84(2Рос=Б2ш)
Ш 96

сб

*Кәүсәрия Шәфикова*

# АЧАМ КҮҢЕЛ САНДЫГЫМНЫ

*Шигырьләр*

84(2Рос=Баш)6
Ш 96





Ц Б С Янаульского
района Баш. АССР
абонемент

# ҮЗЕМ ТУРЫНДА

Гүзәл Башкортстанның Яңавыл районы Исәнбай авылында, 1948нче елның 9нчы ноябрендә туганмын, әткәмнең исеме Фидаи, әнкәмнеке – Тәскирә. Гаиләдә ике кыз бала булдык, мин – беренчесе, 1950нче елгы сеңелем Илгизә бар. Якты дөньяга килгәч әнкәй ак биләүгә биләсә дә авыр язмыш мине үз бишегенә салып тирбәткән. Яшем генә тулып узган, йөгереп йөргән мин сабый, “Полиомиелид” авыруы белән көрәшә башлаганмын һәм ул көрәш бүген дә дәвам итә. Өшкерүче әби-бабайлар да, медицина да авыруым алдында көчсез булып чыктылар, ә мин бөгелсәм дә сынмадым. Аякларга басып йөри алмауны зур бәхетсезлек дияргә буладыр, ә мин – бәхетле, күз дә йоммыйча менә нәрсә әйтәм: Бәхет – кояшлы дөньяга тудырганнары өчен әткәң - әнкәңә рәхмәтле булып, тормышка файдалы кеше икәнлегеңне белеп, шатланып яшәү! Кулымда каләмем бар, хөрмәтлемен, тагын ни кирәк?! Әйе, авырлыклар дәрьясында йөзәм, Ходай кайгы – хәсрәтле итеп яраткан мине, шул ук вакыт, көчле дә иткән, иҗат кешесе булуым белән көчлемен, инде менә 37 ел шигырьләрем, нәсер, хикәяләрем басылып тора, күп җырларым яңгырый, туктаусыз эшлим, зар елап утырырга һич кенә дә вакытым юк. кайгыга күз яшемне күрсәтмим, ә бит, әткәй - әнкәйсез калуым, туган - үскән авылымнан китүем, никахлы тормыш иптәшем Рәфис белән әлегә бергә яши алмавыбыз, инде 6 ел җиде ятлар тәрбиясендә булуым зур сабырлык сорый, әле бирешмим кебек. Бүгенге көндә янымда Бөрҗән кызы Әнисә Ягафарова бар, туганнарым, күршеләрем бик тә игътибарлылар. Яңавыл шәһәрендә яшим, фатирымда бар уңайлыклар да бар, район Хакимият башлыгы Назир Заһит улы Зиязовка, халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлеге начальнигы Клара Зыя кызы Гәрәевага рәхмәтем зур, алар хәстәрлеге булмаса яшәү бик авыр булыр иде, мин бүген: ”Аллага шөкер!” – дип әйтә алам. Гомер көзем җитте, тирәкләрем алтын яфраклы, өлгергән җимешләремнән авыз итегез!

Кәүсәрия Шафикова.
2007 ел.

***

Авылда ир бала туса,
Шатланып уйлап алам:
Солдат хезмәтеннән кайткач,
Игенче булыр әле ул,
Бәхетен зур ит, Аллам!

Авыл яшәр, ир балалар
Яңарта йорт -нигезне.
Җилләрдә дә, давылда да
Җилкән киреп әйләнер ул,
Тормыш дигән диңгезне!

Авылда ир бала туса,
Чиксез ышаныч арта.
Үткәннәрне сагынсам да,
Соңгы юлны уйласам да
Күңелне авыл тарта!

***

Адаштың хис -бураннарда,
Ишетмәдең сүзләремне!
Ах, ялгыштың, шушы халәт
Өзеп ала үзәгемне.

Үкенерсең, әле минем
Шул көннәрне күрәсем бар.
Күңелеңдә әрнеп торган
Яраларга өрәсем бар!
Көч җитәрме?

***

Авыр хәлдә әткәй, алга түгел,
Яши кебек соңгы көннәрен.
Кырау суккан инде, җил куырган,
Яшәүгә ямь бирер гөлләрен.

Авыртына, ялгышып та сөйли,
Мәрхүмнәрне дәшә янына.
Яшеннәрдәй үтеп киткән гомере
Килә торгандыр күз алдына.

Әнкәйсез дә калдык, әткәйсез дә
Калабыз, без ике кыз бала.
Әткәй - әнкәйдән соң шулай икән:
Күз яшьләре, Кояш, Җир кала!

Кояш күреп Җирдә яшәгәнгә
Рәхмәтлебез әткәй - әнкәйгә.
…Хәле авыр, инде озакламас,
Бер генә көн булса да, дим, тагын,
Яшәү бирче, Раббем, әткәйгә!

***

Бар мине дә рәнҗеткәннәр,
Үкенерләр.
Беркөн килеп: “Гафу ит!” –дип,
Үтенерләр.

Кичерермен, үлмәм күңел
Ярасыннан.
Тик котылмас алар Ходай
Җәзасыннан!

***

Авыр сулап куясың да
Иреннәрең тешлисең.
Бәреләсең -сугыласың,
Әллә ниләр эшлисең.

Күзләреңдә моңсулык бар,
Утлар өтә җаныңны.
Ятлар тартып алды мәллә
Өзлеп сөйгән ярыңны?

Хисләреңдә адаштыңмы,
Үкенеп үксүеңме?
Көтепләр алган идем бит
Гөл булып үсүеңне.

Кырау тигән чәчәк кебек
Башың түбән игәнсең,
Ни хәсрәтләр күрер өчен
Бу дөньяга килгәнсең.

И, кыз бала!

## АКЫЛЫМА

Көчеңдә бул,акыл,әле миңа
Гомер буе кирәк булачаксың.
Авырлыклар килеп туган саен,
Минем өчен терәк булачаксың.

Адашмаска тормыш юлларында,
Үкенмичә генә яшәр өчен,
Син кирәк бит, акыл, ул гынамы
Син җиңәргә тиеш хисләр көчен.

Сулар һава кебек кирәксең син,
Көн дә кирәк, акыл, көчең җуйма.
Синең белән яшим, зәгыйфьләнеп,
Бәхетемнән мәхрүм итеп куйма!

***

Ак кыш, ерак юлга чыгып
Бураныңда калдым.
Синең ыжгыр җилләреңнән
Бер җыр отып алдым.
Юлдашым –җыр, кар -чәчәкле
Минем тирә -ягым.
Әй, ак мизгел, өзелеп -өзелеп
Сиңа гашыйк чагым.
Иңнәремдә җем -җем килә
Энҗе -мәрҗәннәрең.
Бүген синдә генә күрәм,
Дөньяның бар ямен.
Аклык, сафлык, ялкын белән
Җанның тулы мәле.
Ак кыш, әйдә бер булмаса
Яшел яфрак ярыр язны
Көнләштерик әле!

***

Аракыны кемнәр уйлап
Тапкан соң, кемнең эше?
Коточкыч бу, аракы һәм
Упкын читендә – кеше!

Яшь әле ул, өлгермәгән
Кылырга бер матурлык.
Кешедән кирәк тормышка
Матурлык вә батырлык.

Бар дөньяга ишетелсен,
Хәвефләнеп чаң сугам:
Ярдәмгә соңламыйк, кеше,
Упкынга төшсә – чыгалмас,
Чыкса да уттан -судан!

## АК ТӨС

Кар ява, тәрәздән
Алалмыйм күземне.
Бу мәлдә иңенә
Кар сарган тал итеп
Тоям мин үземне.

Кар ява, шатлык бу:
Яраткан төсем –ак.
Ак төс – ул ак биләү,
Кайгыдан еларга
Белмәгән сабый чак.

Ак төс – ул саф сөю,
Ак төс –ул ак чәчәк.
Хыялым күгендә
Балкыган аклык бар,
Ул – минем киләчәк!

***

Артык авыртынмаганда,
Бүлмәм җылы, якты чакта,
Бер түгел, мең шатланудан
Язам, тормыш, синең хакта.

Борчылганда, учлап – учлап
Даруларны ашаганда.
Алсам кәгазь белән каләм,
Бер җиңеллек тоям җанда.

Каләмемне куймыйм кулдан
Ут –дарьямы кичкәндә дә.
Ялкынланып җырлар язам
Бозлы сулар эчкәндә дә.
Былбыл да бит талда була,
Көчле җилләр искәндә дә!

***

Акылсыз: «Мин акыллы!» –ди,
Акыллы сүзсез кала.
Ул да бит, мин акыллы, дип,
Кычкырып әйтә ала.

Юк, әйтми, булган акылын
Ник чәчсен искән җилгә!
Шул акылда бар ышаныч,
Авырлык басса иңгә!

Акылсыз юлдан кем китсен,
Акыл барда янәшә!
Акыл белән яшәгәнне
Якты киләчәк дәшә!
Акылсыздан акыллыны
Аера белеп яшә!

Сабый чагың үткән инде,
Күптән тәпи киткәнсең.
Соңлаганчы уйлап кара,
Син кемне үз иткәнсең?!

## АРТЫК ГОМЕР

"Артык гомер!" –дигән сүз бар,
Кемнәр әйтә ул сүзне?
Яшәүдән кем туйсын инде,
Гомер озынлыгы бары–
Ачып йому бит күзне!

"Артык гомер!" – дигән сүзне
Әйтәләр шул ул аны.
Кадерсез, хөрмәт күрмәгән
Өлкән яшьтәгеләр әйтә,
Әрнегән чакта җаны.

## АКЫЛЫМ ҖАВАБЫ

Язмышымны каргаганым
Булмаган иде әле.
Бүген күз яшьсез булмады,
Хәлемнең шундый мәле.

Ярдәм кулын сузучыга
Мохтаҗ булдым мин бүген.
Каплап алды кара болыт,
Кояшсыз калды күгем.

Дуслар күп, туганнар бар, дип,
Әйтергә була аны…
Каялар соң? Дөрес җавап
Телемгә телә җанны:

Кемнәрдә кемнәр кайгысы,
Көрәш, сиңа бит авыр!
Күз яшең түгел, җиңүең
Матурлык булып калыр!

***

Бар яктымнан мине мәхрүм итте
Күкләремә кара болыт тулып.
Бу юлы да мин җиңәргә тиеш,
Исәм әле, исәм җилләр булып.

Бу юлы да мин җиңәргә тиеш ,
Бөгелмәскә кирәк, сыгылмаска.
Бер егылсам –торып баса алмам,
Егылмаска кирәк, егылмаска!

Авырлыкны җиңгән батырлык –
Тиңе булмый торган матурлык!

## АНТЫБЫЗ БАР

Халкым, татарым, мин синең
Газизләрдән-газиз балаң.
Синең моңың –минем моңым,
Минем Аллам –синең Аллаң.

Татар иде әткәм -әнкәм,
Тәнем татар, җаным татар.
Иманыма кагылсалар,
Рәнҗү яшем каты тотар!

Без күп, энҗе-мәрҗән булып
Җемелдибез җир йөзендә.
Антыбыз бар, юк, тел үлмәс,
Татар тора үз сүзендә.

Үз телемдә шигырь язам,
Барыр юлым ачык, озын.
Бәхет бит бу: тормыш үзе
Алкышларга күмә бүген
Каләм тоткан татар кызын!

***

Бәхет ул кеше булып яши белү,
Кеше ул тирен түгеп икмәк ашый.
Тир түгү –хәләль ризык, хәләль байлык,
Тир түккән – иртә таңнан эшкә башлый.

Чын бәхет –авырлыклар аша килә,
Авырлык –көрәш белән җиңеләчәк!
Көрәш син, бәхет сиңа колач җәяр,
Каршылар шатлык белән зур киләчәк!

***

«Апа, аякларың кая,
Нигә басып йөрмисең?
Эшкә дә бармыйсың, никтер,
Якын күршеләреңә дә
Хәл белергә кермисең.
Көтү дә каршыламыйсың,
Бармыйсың син суга да.
Көн буена, гел язышып
Утырасың арбада!»
Дүрт –биш яшьлек балаларга
Җавабым күптән әзер:
«Сезнең кебек кенә чакта,
Әнкәйне тыңламаганмын,
Мин кул-аяксыз хәзер!»
Алдыйм , әнкәй зарланмады
Минем балачак белән.
Нәниләргә җавап сүзем
Файдага булыр, беләм.
Файдага гына алдыймын,
Мәгълүм бу барыгызга.
Карыйм әнкәй рәсеменә,
Ә ул миңа әйтә кебек:
«Кара, син әйләнә күрмә
Алдаша торган кызга!»

***

Бар, ышанып, алданганым,
Бар бурычка алганым.
Бөеклегем шул мин кеше,
Юк хыялсыз яшәгәнем,
Юк өметсез калганым!

***

Апрель ае, кар суының
Ярлардан ташкан чагы.
Күңел кошының талпынып,
Күкләргә ашкан чагы.
Иңнәрдән коча апрельнең
Салкынча назлы җиле.
Яз – ялкыннан яратылган
Сөю – мәхәббәт иле!
Апрельдә кошлар туй итә,
Апрелдә Тукай туган!
Шуңадыр, дим, дөнья тоташ
Шигъри ямь белән тулган!
Әллә нинди үзгә хуш ис,
Сулап туймаслык һава.
Умырзая таҗларына
Кояш нурлары ява.
Апрель ае– җырлы аем,
Йокысыз калган чагым.
Талда бүрткән бөреләрдән
Яшәр көч алган чагым!

## БАЛА ТУДЫ

Бала туды! Иңләп бар дөньяны
Бу шатлыклы хәбәр таралды.
Яңа кеше сулый, елый, яши,
Димәк, яңа язмыш яралды.
Бу язмышның көне кояшлымы,
Күге тулы болыт түгелме?
Бала туу – шатлык, шушы шатлык
Һәрвакытта шулай тирән уйлы,
Мең борчулы итә күңелне.

## АТ АТЛАНЫП ЧАБАРСЫҢ

(Юнирга)

Тып-тып атлап йөреп киттең,
Уенчыгың кулыңда.
Хәвеф-хәтәр очрамасын
Берүк үтәр юлыңда.
Хәерле юл сиңа, сабый,
Нык бас, егылып калма.
Егылсаң да сикереп тор,
Җаныңа курку алма.
Син ир бала, ат атланып
Болыннарда чабарсың.
Юлларыңнан тайпылмасаң,
Бәхетеңне табарсың.
Әлегә син– нәни чебеш,
Чип-чип-чип килгән чагың.
Юкка да елап, юкка да,
«Атьти –атьти!» –дигәнгә дә
Чыркылдап көлгән чагың.
Тәпи киттең, бар дөньямны
Илаһи бер нур алды.
Күз алдымда әле генә
Чын матурлык яралды!

## БӘХЕТЛЕМЕН

Әйтә алмыйм, тыныч яшимен, дип,
Җил-давыллы минем уйларым.
Минем тормыш тора хәтерләтеп
Һәрчак шаулы диңгез буйларын.

Әйтә алмыйм рәхәт яшимен, дип,
Гомер буе сыныйм үземне.
Бәхетсезлек, сине җиңеп әйтәм:
«Бәхетлемен», дигән сүземне!

***

Ат, йөгәнен чәйнәп, йөген тарта,
Чыбыркылый хуҗа, җәлләми.
Карап торам таныш бу халәткә,
Аермабыз юк бит әлләни.

Ат арбасы йөкле, минем җанга
Бер-бер артлы килә авырлык.
Иреннәрне тешлим канатканчы,
Ходаемнан сорыйм сабырлык.

Тормышның бар шундый кырыслыгы,
Ай-ваеңа синең карамый.
Кеше булып калыйм, ә аткамы–
Ат булмыйча аңа ярамый!

***

Баймын, ләкин минем байлык,
Алтын-көмештән түгел.
Үз телем бар, үз моңым бар,
Үз җиремдә икмәк үсә,
Шатлыктан җырлый күңел.

Баймын, сөю кошым исән,
Бар хыялым тулпары.
Өлешемә тигән бар да
Салкыннары калтырата,
Өтеп ала утлары.

Бар да хәлаль, үземнеке,
Бар йокысыз төннәрем.
Бар кайгыдан кара көйгән,
Шатлыклардан балкып торган
Бүгенгедәй көннәрем.
Баймын!

## АЧАМ КҮҢЕЛ САНДЫГЫМНЫ

Ачам күңел сандыгымны,
Күрсәтердәй нәрсәм күп.
Бар ул миндә чәчәкле җир,
Бар кояшлы зәңгәр күк.

Тау кадәрле бәхетем бар,
Шатлыгым бар, бар да чын.
Хәтерләтә күңел дөньям
Сандугачлар оясын.

Юк, ал да-гөл түгел бар да:
Карасы бар, агы бар.
Мин бит гомер юлы үтәм,
Хәлнең төрле чагы бар.

Күңелемнең биген ачам,
Барысын да күрегез.
Минем бөтен байлык – яшәү,
Соклансагыз сокланыгыз,
Тик тимәсен күзегез!

## БӘХЕТ КИРӘК БУЛСА

Үз бәхетен таба кеше,
Бәхет ул ерак түгел.
Бәхетне эзләргә кирәк
Уфтанып, елап түгел.

Хезмәт тирең тамган җирдә
Үсәчәк бәхет гөлең.
Тормышка ямь булып калса
Яшәлгән якты көнең,
Төшләреңдә саташмассың,
Бәхетле булыр өнең!

***

Ашыгып китмә әле, кыш,
Аерма шатлыгымнан.
Күңелемә җем-җем энҗеләр
Сибелә аклыгыңнан.

Ап-ак бәсле тал -тирәкләр
Күзләремне иркәли.
Табигатьнең бер кайгысыз
Чагы шушы микәнни!

Хәйранмын, сафлык, гүзәллек
Әйләнәмдә -тирәмдә.
Мәхәббәт, җыр, яшәү үзе
Бар менә шушы ямьдә.

Ашыгып үтмә әле, кыш,
Түзәрмен салкыннарга.
Аклыгыңны алыштырмыйм
Тау кадәр алтыннарга!

***

Бәхет кошы канатлы бит:
Очып килә, очып китә.
Бәхет кошың килер юлда
Искән җилләр булса киртә,
Киртәләрне җимерергә
Күп кирәкми, давыл кебек
Көчле булсаң шул да җитә!

«Миңа бәхет бир, Аллам!» – дип,
Теләк теләү генә җитми.
Намусыңны таптамасаң,
Ялгыш юлдан атламасаң,
Китми синнән бәхет, китми!

БЧЛ – 43138



ЦБС Я... района ...
абонемент

## БАЗАРДА ЙӨРЕП КАЙТКАЧ

Савытларга утыртылган
Гөл саталар хатыннар.
Гөлләр булган җирдә, хәтта,
Кирәк түгел алтыннар!

Сулар сибеп үстергәннәр,
Чәчәк аткан гөлләре.
Матурлыкны сату, шуңа
Калган микән көннәре!

Әнкәм үстергән гөлләр дә
Шау чәчәк ата иде.
Гөл сатмады минем әнкәй,
Бушка тарата иде.

Гөл саталар, гүзәллеккә
Ничек бәя куярсың!
Шаклар катып бу хәлләргә,
Акылыңны җуярсың!

Тәрәз төбендәге гөлләр
Күзләремә багалар.
Беркем бәя биралмаслык,
Минем шатлыгым алар!

***

Кайгы килә, ничек инде
Шатлыгы килми калсын!
Кем кайгыдан өши бүген,
Минем сүнмәс өметләрем
Ялкынынннан ут алсын!

***

Бар иде ул минем ямьле язым,
Яшел иде дөньям, яшел иде.
Гашыйк булдым, ялкынланып яндым,
Өлешемә үз дигәнем тиде.

Килеп җитте җәем, чәчәкләрен
Өзеп алып такыялар үрдем.
Гел бәхетем генә назламады,
Тәкъдиремә язылганны күрдем.

Гомеремнең алтын көзе җитте,
Уңышларны барлыйм, сөенечле.
Шушы яшькә җитеп юк бер хатам
Үкендерә торган, көенечле.

Кышларым да ерак түгел инде,
Беренче кар минем чәчләремдә.
Юк, картаям, димим, бу сүзләрем
Булса булыр туксан яшьләремдә.

Бирсен Ходай, озак яшәү бирсен,
Бик күрәсем килә ак кышымны.
Бу тормышта җыр итәсем килә
Дүрт мизгелдән алган балкышымны!

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ АЛГАЧ

Туганнары котлап килде,
Шатланыштылар бергә.
Менә, дусларын югалтты,
Күтәрелде дә үргә.

***

Барам, юлда туктап калмыйм,
Алда якты, кояшлы көн,
Йолдызлары зәп-зәңгәр төн!

Хыялларым әйди алга,
Колач җәя киләчәгем,
Анда минем күрәчәгем!

Гомер генә булсын берүк,
Шатлыклар да, кайгылар да–
Өлешемә тияр бар да.

Алга барам, алда яшәү,
Әйе, үлем дә бар анда,
Утлар берчак сүнәр җанда.

Бүген әле зур юлда мин,
Күкрәк куйдым җил-давылга.
Җиңү белән барам алга!

## БАШЫҢ ТҮБӘН ИМӘ

Сөю уты сүнә, бәхет кошы үлә,
Хыял канатлары каерыла, сына.
Юк, тиз генә түгел, еллар үткәч кенә,
Дәва табып була йөрәк ярасына.

Яңа сөю килә, яңа бәхет туа,
Хыялларың янә әйди сине алга.
Дөнья әнә шулай яратылган, аңла!

## БАШКОРТСТАН

Башкортстан, бәйрәм итәсең син
Чын дуслыкка ия булуны.
Менә инде җәбер күрми яши
Үз халкыңның ничә буыны!

Башкорт җире, шаулап чәчәк аттың,
Русиянең үтеп түренә.
Бүген әнә, бар да елмаябыз,
Күтәрелеп шатлык үренә.

Башкорт иле, синең курай моңың
Русиягә инде дан булып.
Тир түгелгән өчен, бәхет үзе
Тамырлардан ага кан булып.

Башкортстан, үзең син– бер дөнья,
Яшәү яме белән тулган җир.
Русиянең җәүһәр ташы булып
Яшә әле, яшә, Туган җир!

***

Бугазымнан алсаң да, чир,
Юк әле,юк, бирешмим.
«Теге дөньяга кит», – дисең,
Синең белән килешмим.

Нигә китим, миңа әле,
Кояшлы дөнья кирәк.
Матур эшләрем белән мин
Тормышка үзем кирәк.
Җырлыйсы җырларым бар, дип,
Күкрәктә тибә йөрәк.

## БАШКОРТСТАН БӨРКЕТЛӘРЕ

Башкортстан, кыялардан
Күтәрелде бөркетләрең.
Горурланып әйтәм, бар ла,
Бөркетләрдәй егетләрең!

Бөркетләр бит юкка гына
Канатларын какмый җилгә.
Үстерәсең малайларны
Терәк булсыннар дип илгә.

Бүген солдат хезмәтенә
Ничә улың китә әнә.
Исән –имин булуларын
Күрү насыйп булсын янә.

Башкортстан, күреп яшә
Улларыңның батырлыгын.
Ә егетләр–уяу саклар
Башкортстан матурлыгын!

***

Бүген дә бер авылдашым
Мәңгелеккә йомды күзен.
Кылды микән матур эшләр,
Калдырдымы якты эзен,
Исән чакта күрсәттеме
Гөлләргә тиң итеп үзен.
Бу тормышка сөю белән
Әйттеме ул соңгы сүзен?
Ялгышсыз да булмагандыр,
Соң инде, соң, күреп булмый,
Ап-ак җәймә каплый йөзен!

## БӘЙРӘМДӘ

Яңавылда бәйрәм бүген,
Башкортстан бәйрәм итә.
Бии гармун басмаклары,
Үзәк кылын чиртә-чиртә.

Мәйдан тулып моң агыла,
Мөлдерәп лә күңел тула.
Өзелеп -өзелеп сагынудан да,
Шатлыктан да шулай була.

Әйтерсең лә сабан туе,
Гөрли бәйрәм тантанасы.
Монда көйнең борынгысы,
Монда көйнең өр-яңасы.

Тальян моңын сандугачлар
Тыңлый бүген кунып талга.
Мәңге яңгырар тормыш җырын
Тыңлый алар калып таңга.

Әй, гармуннар, тынмагыз ла,
Яңгырасын җырларыбыз.
Теләгем шул: язларыбыз
Бәйрәм алып килсен өчен,
Имин булсын җир шарыбыз!

## ЭЗЛӘРЕҢДӘ ГӨЛЛӘР ҮСӘР

"Мин – кеше!", – дип күкрәк сугу
дөрес булмас,
Ярдәмеңә мохтаҗлар бар, кулыңны суз.
Кеше булсаң әгәр, читкә тайпылмыйча
Бу тормышта син мактаулы юлыңны уз.

## БЕЛ

“Башны имәм!” – дисәләр дә,
Ияләр, тормыш усал.
Шулай да дим, үз-үземә:
“Син үз сүзле булып кал!

Башыңны да түбән имә,
Күз яшеңне чыгарма.
Ходай үзе ярдәм бирә
Барсына да чыдарга.

Әнә, бөгелеп үскән агач:
Яфраклары ямь-яшел.
Авыр язмышы алдында
Башын имәгән ул, бел!”

## БЕР ТАНЫШЫМА

Мин ул сөю утларында
Ничек кенә янмадым!
“Яратам!” – дип шигырь яздым,
Акылымнан язмадым.

Тетрәде җаным,”Яшисем
Килми!” – дигән сүзеңнән.
Мең газапка мең сабырлык
Таләп ит үз-үзеңнән.

“Яратам!” – дип, әйдә, яшь түк,
Яраткан өчен яшә.
Ишет, сиңа мәхәббәтне
Мәңгелек җыр итә алган
Минем йөрәгем дәшә.

***

Берәү миннән бер сүз көтте,
Мин әйтмәдем, үкенәм.
Сиңа әйттем, инде бүген:
“Оныт!” – диеп үтенәм.

Бәхет кошың булмаганмын,
Тирәгеңә кунсам да.
Юк, җылыта алмаганмын,
Гел яныңда булсам да.

Бу коточкыч! Ах, үзгәртеп
Булсын иде дөньясын.
Мәхәббәтем сандугачы
Адашып ла калган, үкси
Табалмыйча оясын.

## БЕРӘҮ ТУДЫ

Дөнья, син яралган чакта
Чип-чиста булгансыңдыр.
Җан ияләре яралгач
Үзгәргәндер синең йөзең,
Чүп-чарга тулгансыңдыр.
Кояшка карап төкергән
Бәндәләр яши җирдә.
Имансыз бул икән шулай,
Аңсыз бул икән, дөньяга
Яшәргә диеп кил дә!
Дөнья, кан, күз яше белән
Син инде күптән тулы.
Карадан кара булырмы,
Гөл булып тамыр җәярме,
Әле дә берәү туды!

## БӘХЕТ КИЛЕР

Менә тагын бер тулы ел
Үткәннәрдә торып калды.
Инде Яңа елның кары
Иңнәремне сырып алды.

Талгын гына яуган карны
Зур шатлыгым итеп күрәм.
Тулпарымның ак ялларын
Толым-толым итеп үрәм.

Хыял атым җилдәй җитез,
Барган юлы – киләчәккә.
Ашкынуым булсын берүк,
Тик бәхетле күрәчәккә.

Бүген һәркем күңеленә
Якты иңә өмет булып.
Димәк, карлар яуган кебек
Бәхет килер дөнья тулып.

***

/Г. Ләйсәнгә/

Язларың үтеп киткәнгә
Боекма, җәйләрең бар.
Яшәгәч яшә гөл булып,
Көнгә бак, яфрагың яр.

Чәчәкләрең кызыл булсын,
Булсын ул ак, булсын ал.
Карлы яңгыр яуганда да
Чәчәкле гөл булып кал!

## БӘХЕТ ЮРАДЫМ

Чыгып, кышкы урамны бер
Әйләнеп кердем.
Җырларым итеп җырларлык
Матурлык күрдем.

Җемелдәп ята карлы юл,
Агачлар ап-ак.
"Кышның сихри яме бар!" – дип,
Әйтүләре хак.

Хыял дөньясыдай якты
Шәһәр урамын
Ураганда һәркем өчен
Бәхет юрадым.

Күзләремне иркәләде
Андагы аклык.
Дөньяның үзе кадәрле
Миндәге шатлык.

## ГАФУ ҮТЕНӘМ

Шәһәремне мактап шигырь язган идем–
Төн буена авылымны төштә күрдем.
Ак каеннар кара көйгән икән димен,
Яшеллекне эзләп,үксеп елап йөрдем.

Авылдашлар эндәшмиләр, ачулылар,
Өзгәләнәм, бөтен гаеп миндә имеш.
Коляскамда икәнмен, дим, үзем генә,
Гаебемне танып, авыл урамыннан
Китеп барам башны түбән игән килеш…

## БӘХЕТЕМ ЗУР

Читтә торсын аллы-гөлле
Чәчәкле болыннары.
Дәшә бүген туган җирнең
Иген үскән кырлары.

Бар нәрсәгә караганда
Бүген басу ямьлерәк.
Нәрсә бар соң ипикәйдән
Кадерлерәк, тәмлерәк!

Алтын дулкын яра-яра
Кыр буйлап килә кораб.
«Бәхетем зур» диеп ничек
Әйтмәссең, бу кырлар аша
Килер көннәргә карап!

***

Биргәч бирә икән Ходай,
Болай да бик күп иде.
Беләгемне карады да
Табиб: «Сынган бу!» -диде.

Сызланасы тәнем булгач,
Ни әйтәсең, күрәчәк!
Белеп булмый, ниләр белән
Килер әле киләчәк!

Яшәү – бәхет, тик йөрәгем
Тибүеннән тынмасын.
Әйдә, сөяк сынса сынар,
Рухым гына сынмасын!

***

Бәхеткә ышан, бәхет бар,
Ләкин ул төшми күктән.
«Бәхетең үз кулыңда!» –дип,
Әйткәннәр аны күптән.

Белем яула, хезмәт күрсәт,
Кара булмасын уең.
Бәхетне ал син үрелеп,
Җитмәслек түгел буең.

«Мин бәхетле!» -дигән сүзем
Сәер ишетеләдер.
«Аяксыз-кулсыз бул да!...» –дип
Бәлки күпләр көләдер.

Кеше матур эше белән,
Һәрчак бәхеткә ия.
Башкача яши белмимен,
Исемем изге китаптан,
Мин миңле Кәүсәрия!

***

(Г. Раиләгә)

Әйтерсең лә, кулларымда
Тотып торам кояшны.
Җылы тоям, чәчәкләрдә,
Күрәм синең карашны.

Рәхмәт, дускай, ал чәчәкләр
Бүләк иттең син миңа.
Бары гүзәллектән генә
Яралган минем бу җырым
Бүләгем булсын сиңа!

## БӘХЕТЛЕ БУЛЫГЫЗ

(Роза белән Әлфиткә)

Пар күгәрчен оя кора,
Кылыйк изге догалар.
Җил-давылга әйләнмәсен,
Имин булсын дөньялар.

Гөр-гөр килә пар күгәрчен,
Оя булыр балалы.
Бар булсыннар, сау булсыннар,
Булмасыннар яралы.

Пар канатлар каерылмасын,
Сөю җуймасын төсен.
Күгәрченнәр оя кора –
Бәхетле булыр өчен.

## БҮГЕН

Көнне – кояш якты итә,
Күңелгә – шатлык кирәк.
Тик тормышта әллә нигә
Шатлыклар була сирәк.

Болытлы көн кочагында
Гөлләр боегып кала.
Әйтерсең лә, шул чәчәкләр
Әнисез калган бала!

Ятим бала, ялгыз ана
Күз алдымнан һич китми,
Болытлар куера гына,
Күңелгә шатлык җитми!

## БӘХЕТЛЕ ӨНЕМ БУЛ

Сусатма назыңа, сусатма,
Суларган сусаган гөл итмә.
Китсәләр кошлар гел китсеннәр,
Син китмә, син китмә, син китмә,
Суларга сусаган гөл итмә!

Чәчәкле гөл булып яшәрмен,
Нур сибәр кояшлы көнем бул.
Үксеткән төшләрем булма син,
Бәхетле өнем бул, өнем бул.
Нур сибәр кояшлы көнем бул!

Мин – сине, син мине сөюдән
Тормышта мәңгелек ямь тусын.
Яшәсен мәхәббәт гөлләре,
Күзләргә шатлыклы яшь тулсын.
Тормышта мәңгелек ямь булсын!

## БҮГЕН ЯЗНЫ КӨТМӘСӘМ ДӘ...

Кошлар китте, саубуллашу
Җырымны көйләп калдым.
Күңелемне тутырганчы
Көздән янә моң алдым.

Салкынайтты, алтын көзнең
Үтте алтын чаклары.
Вакыт җитте, инде явар
Яңгыр катыш ак кары.

Бүген язны көтмәсәм дә,
Йөрәгемне җилкетеп,
Каз каурые алдым кулга,
Килер кыштан җыр көтеп!

## БҮГЕНГЕ КӨН

Язмаса да камил шигырь,
Бик еш чыга китаплары.
Шагыйрь булу, фу, чипуха,
Акчаң гына булсын бары!

Бу бүгенге заман белән
Юк, килешми минем күңел.
Шигъри хистә - илаһи көч,
Шушы хисне, шушы көчне
Сатып алу мөмкин түгел.

Гарип шигырь белән тулган
Безнең көндә әле тагын
Урлашу бар. Бар күргәнем
Шигъриятнең газаплардан
Үксеп өзгәләнгән чагын.

Тормыштагы бу ямьсезлек
Бик озакка китәр микән?
Шундый шагыйрьләрне Мостай,
Әнгам, Илдар абыйларның
Рухы гафу итәр микән?

***

Гомеркәйләр шулай үтә икән,
Сары яфрак сибә ак каен.
Сагынып ул елый юкка гына,
Яшел бөре ачкан чаккаен.

Әй, ул яшел чаклар, табигатьтә,
Әйләнә дә килә ел саен.
Күзен сөртеп әби әйтеп куйды:
Ник булмадым икән назлы җилдә
Иркәләнеп яшәр бер каен!

***

Бүгенгедәй хәтеремдә:
Бер сүз әйттең пышылдап.
Беренче апрель булса да
Юк-юк, әйтмәдең алдап.

Яз иде, язгы ялкында
Кайнаган чагы канның.
Мөлдерәмә хисләр белән
Яшәгән чагы җанның!

Безне ташлап китмәде яз,
Әле һаман бергәбез.
Әйе -әйе, сөюне без,
Тапсыз саклый беләбез.

Беренче апрель көнне син
Әйттең: «Яратам!» –дидең.
Язлар белән килдең миңа,
Бәхетем булып килдең!

***

Гомер буе бисмилласыз булгансың син,
Иблис синең күңелеңә кара яккан.
Миндә иман нуры балкый бала чактан.

Ходаема тапшырам, дип, юлга чыгам,
Аллакаем, ярдәм бир дип, эш башлыймын,
Шуңа да, дим, адашмыймын, ялгышмыймын.

Иблис сине әйдәп бара караңгыга,
Минем юлым якты таңга каршы бара.
Якын килмә, күк белән җир безнең ара!

## БҮӘ БУЕНДА

Ярларына тулып Бүә ага,
Тирә-ягы аның тал-тирәк.
Шушы матурлыкны бер җыр итеп
Яңгыратсын әле ут-йөрәк.

Карап торам йөгрек дулкыннарга,
Акчарлаклар чыр-чу киләләр.
Ак болытлар йөзә, әйтерсең лә,
Хыялларым җилкән кирәләр.

Искән җилдә бары наз тоямын,
Туган як бит, туган яккаем.
Чәчәкләре шатлык бүләк итсә,
Сафлык бүләк итә ак каен.

Җикән камыш, ак чук төнбоеклар
Җырларыма керми каламы!
Табигатькә гашыйк җаным барда,
Каләмемне ташлый аламмы?!

Ярларына тулып Бүә ага,
Түгелер дә кебек чайпалып.
Рәхәт дулкын кага күкрәгемә,
Шатлыклардан торам чайкалып.

## ШОМЛЫ ТӨН

Яңа туган бала елый, каян бу,
Тыңлап ята торгач уйлар чуала.
Бәби бармы берәр күрше фатирда,
Ишек төбендә түгелме бу бала!

***

Бүләк иттең чәчәкләрнең
Нәкъ мин яратканнарын.
Әллә нигә яратам шул
Чәчәкләрнең алларын.

Күрү белән чәчәкләрне,
Дөньяма ал нур тулды.
Сихри нурдан күкрәгемә
Бер көч иңгәндәй булды.

Чәчәк итеп өзгәнсең син
Күңелең матурлыкларын.
Җилфердәп таҗлар җемелди,
Сипкәнсең таң чыкларын.

***

Высший сортлы оннар булсын алар,
Булсын, ләкин торсын бер читтә.
Тиңе булмас тәмгә ия булган,
Бодай ипиенә ни җитә!

Бодай үскән кырлар якын миңа,
Тәмле ис бар искән җилендә.
Алтын -юктыр, алтыннан да кыйммәт
Бодай үсә туган җиремдә!

Авылыма кайттым, кырга чыктым,
Авылдашлар бодай урганда.
Бәхет белән дөнья тулган иде,
Минем шушы җырым туганда!
Бәхет булыр ипи булганда!

***

(Г.Илгизгә)

Илгиз хәзер алты яшьтә,
Буталмый гына саный.
Шигырьләрне яттан сөйли,
Күп кенә хәреф таный.

Татарча да, урысча да
Сөйләшә матур итеп.
Көн дә иртән бакчасына
Әтисе йөртә илтеп.

«Папа-мама», –дими Илгиз,
«Әти -әни», –ди һәрчак.
Мин шатланам, димәк, Илгиз,
Хөрмәт иткән өчен телен,
Зур бәхетле булачак!

## ГАДИ БУЛЫЙК

Гади генә булып яшик әле,
Гадилектә була камиллек.
Борыныңны күккә чөйгәнче син,
Як-ягыңа кара иң элек.

Гади генә әнә җир дә, күк тә
Шушы инде яме дөньяның.
Гади генә булып, гүзәллеген
Арттырасың гына син аның.

Яратам мин гади кешеләрне,
Гадиләрдән - гади мин үзем.
Шигырь язам, ярлы күңеленә
Иңсен әле, диеп, тамчы - тамчы
Энҗе - мәрҗәннәрдәй һәр сүзем.

## ГАЕП ТҮГЕЛ

/Яшьләр колагына/

Бисмилланы әйтә - әйтә
Тор син иртән урыныңнан.
Көн буена шат булырсың,
Гел эш килер кулыңнан.

Ипикәйгә үрелми тор,
Бисмилланы әйт башта.
Бисмилласыз нурлар чәчеп
Чыкмыйдыр ул кояш та.

Бисмиллаң белән ишек ач,
Имин булыр йорт-җирең.
Кайгыларга бирешмәссең,
Җиңелер булган чирең.

Бисмилланы әйтеп утыр
Машинаңа, атыңа.
Изге юлың сине илтеп
Җиткерер максатыңа.

Гаеп итмә, белгәнемне
Әйтми, өйрәтми калмыйм.
Үзем иман китермичә
Каләмем кулга алмыйм.

## ГАШЫЙК БУЛДЫМ

Чыктым урам әйләнергә,
Җәйне күреп калыйм, дип.
Бөтен ямен түкми-чәчми
Җырларыма алыйм дип.

Җәй җил булып искән икән,
Эзләп таба алмадым.
Былбылсыз калса да таллар,
Юк, мин җырсыз калмадым.

Сихри моңсулыкка чумып,
Кайтыр якка юл алам.
Сары көзгә гашыйк булдым,
Миләшләр булып янам.

## ГАШЫЙКМЫН

Әйе, тагын гашыйк булдым,
Янам гыйшык утында.
Дөресе шул, гомеремнең
Яратусыз үткәрмәдем
Хәтта бер минутын да.

Гашыйк булып күңелемнең
Бар тынычлыгын җуям.
Бу гүзәллек тормышымнан,
Эзсез югалмасын өчен,
Бер шигырь язып куям.

Шаклар катам, гашыйк булу
Көченең зурлыгына.
Бүген тагын дөрләп янам,
Мөкиббән китеп гашыйкмын
Яшәү матурлыгына!

## ГОМЕР КӨЗЕМ

Гомер көзем, килдем сиңа
Ак чәчәкле язларымнан.
Бүген дә мин сихерләнәм
Мәхәббәтем назларыннан.

Килдем сиңа, юл буена
Яшел җәем озата килде.
Җиле исте талгын гына,
Баш очымда кояш көлде.

Җиңел генә буламы соң,
Тормыш юлын үтүләре!
Тау-ташларны кисү булды,
Сиңа килеп җитүләре.

Гомер көзем, тирәкләрең
Яфраклары алтыннан бит.
Яшәү матур, шуңадыр дим,
Минем йөрәк ялкыннан бит!

## ГОМЕР УЗА!

Бернигә дә борчылмыйча,
Онытып бар мәшәкатьне,
Ашыкмыйча беркая да,
Туктатып куеп сәгатьне,
Утырыйк бер рәхәтләнеп,
Коймак пеште, чәй кайнады.
Юк, яшәгән кадәр яшәп
Булмас, гомер күп калмады.
Һәркемнең бар сөйләр сүзе,
Күргәннәр –тау өемнәре!
Калыйк әле җиңеләеп,
Чишелсен сер төеннәре.

## ГОРУРЛЫГЫМ

Бар бөркетле кыялары,
Каенлы урманнары.
Шифалы яуган яңгыры,
Бар карлы бураннары.
Җиләкле яланнары бар,
Ипикәйле кырлары.
Балы бар, кара алтыны,
Балыклы елгалары.
Егетләре курай уйный,
«Җиде кыз» тора биеп.
И бииләр, челтер –челтер
Тәңкәле түшлек киеп!
Сузылып ерак –еракка,
Бормалы юллар ята.
Аккошлы якты күлләре,
Гөлләре чәчәк ата.
Бу минем Башкортстаным,
Бу минем горурлыгым.
Шөкер, бүген дә җырладым,
Туган җир матурлыгын!

## ДУСТЫМА

Гаҗәпләнер бер ни дә юк,
Яшьлек соң, үтсен ул гел.
Күзләремдә нур бар әле,
Чал чәчләр –ямьсез түгел.
Фотога төшер, йөземдә
Алсулык бар чагында.
Үзгәрермен, гомеремнең
Кышы җитәр, әлегә мин,
Алтын көз кочагында!

***

Гөлләр шатлана, чәчәккә
Төренгән алар бар да.
Гөлләргә яшәргә була
Яңгыр, җил, кояш барда.

Кешегә күбрәк кирәк шул,
Җитми җил назы гына.
Яңгырлар гына әйләнә
Алмый җан азыгына.

Кояш нурларыннан гына
Җылы тапмый кешеләр.
Күңел җылысына мохтаҗ,
Менә минем ишеләр.

Гөлләргә карап уйланам,
Сокланам үзләренә.
Алар: «Сез бит сабыр итә
Беләсез!» – дигән шикелле
Карыйлар күзләремә.

***

Диңгездәге дулкын булдым инде,
Ярдан ярга яшим сугылып.
Утлар булып өтә мине тормыш,
Йә, өшетә бозлы су булып.

Көзге җилләр әле ни генә ул,
Тормыш җиле усал, аямый.
Күрсәтмичә булмый күз яшьләрен,
Ә бөгелеп төшү –ярамый!

## ГӨЛЛӘР ҮСТЕР

Күз алдымнан китми әнкәй бәгърем,
Чәчәк аткан чакта гөлләрем.
Белдем инде, әнкәм исән чакта
Гел кояшлы булган көннәрем.

Колагымнан китми әнкәм тавышы,
Мин ишетәм аны бүген дә:
«Күренеп торсын күңел матурлыгың,
Гөлләр үстер тәрәз төбендә.

Гөл үстергән кеше яман булмый!»
Әнкәм сүзләрендә хаклык бар.
Минем җанда бары җырым итеп
Бүләк итә торган-сафлык бар!

## ГӨЛЛӘР КҮРӘМ

Тәрәзәм төбе тулы гөл,
Бар да көнгә бакканнар.
Кояш нурына назланып,
Матур чәчәк атканнар.

Мин дә әнкәй кебек, ул да
Гөлләр ярата иде.
Авылдашларга үсенте
Гөлләр тарата иде.

Үтәм авыл урамыннан,
Тәрәзләрдә күзләрем.
Гөлләр күрәм, күңелемә
Ак чәчәкле гөлләр якын,
Сагынып кайтам үзләрен.
Әнкәм ап-ак чәчле иде!

***

Гөл-чәчәккә тиңлә мине,
Тиңлә якты язларга.
Ялган түгел, чын мәхәббәт
Хаклы мине назларга.
Иренемдә җиләк тәме,
Күңелемдә ихласлык.
Хыялларым таңдай алсу,
Уйларымда гел аклык.
Күз яшьләрем - лэйсән яңгыр,
Кайгыга юк, баш имим.
Сөйсәм мәңгелеккә сөям,
Юк, бер көнгә мин сөймим.
Җырлы-моңлы минем җаным,
Кыллар нечкә, сак кагыл.
Буйсындыра мине бары
Хисләр түгел, тик акыл.
Мин – хатын-кыз!

***

Дөнья шулай яратылган:
Карасы бар, агы бар.
Шатлык җинәме кайгыны,
Җиңә, җиңгән чагы бар!

Якалашкан чагы була,
Мәхәббәт һәм нәфрәтнең.
Нәфрәт горурлыгы көчле,
Моңа шаһит булдым мең.

Иң көчлесе үлем, диләр,
Юк-юк, яшәү көчлерәк!
Ул көч шунда: мең кат үлеп,
Мең кат терелү кирәк!

***

Давылларга каршы барачакмын
Канатларым сынып калганчы.
Юк, мин чыкмыйм көрәш мәйданыннан
Соңгы сулышымны алганчы.

Кемдер мине тиңләр асыл кошка,
Бик күпләре әйтер: «Батыр!» – дип.
Бу –миннән соң, рухым кабул итәр,
Дөреслек бар монда, без, кешеләр,
Көчле булган өчен матур бит!

***

Әй, кошкай, ояң читенә
Килеп җиткәнсең, сак бул.
«Саклангганны алла саклар», –
Диеп әйткән сүз хак ул!
Син әле бала кош кына,
Канатларың ныгысын.
Юк, оянда утырмассың,
Зәңгәр күктә булырсың.
Очарга өйрәтер анаң,
И шатланып очарсың.
Назлы җилләр белән бергә
Кояш нурын кочарсың!
Уйланып, күзәтеп торам,
Канат җилпеп ала кош.
Их, шуны беләсе иде,
Кайгыларга сала микән,
Ана кошны бала кош!

***

( Гөлсемгә)

Гөлсем җырлый, сандугачлар
Торсын әле бер читтә.
Бу дөньяда моңлы булып
Яшәүләргә ни җитә!

Гөлсем җырлый, күңелләргә
Агыла моң тавышы.
Бәхете таудай, бу аның
Ходай биргән язмышы.

Җыр илендә яши Гөлсем,
Берүк озак яшәсен!
Алтын көзе җиткәч тә ул,
Язлар булып яшәрсен!

***

Елларымны, айларымны,
Көннәремне җепкә тезәм.
Энә белән бармакларга
Чәнчеп-чәнчеп алам, түзәм!

Сәгатьләрем, минутларым,
Секундларым бик кадерле.
Күп яшәдем, яшәр идем
Әле тагын шул кадәрле.

Биш, егерме, илле алты,
Елларымны тезәм шулай.
Юк ла, энҗе-мәрҗәннәрдән
Төймә генә тезәм бугай!

## ЕГЫЛМЫЙЧА КӨРӘШӘМ

Елаганның яшен сәртәм,
Үксегәндә дә үзем.
Димәк, Ходайның кодрәте–
Юатып әйткән сүзем.

Кемнәр тәмам хәлдән тайган -
Шуларга көч өләшәм.
Күрсеннәр, мин әле шөкер,
Егылмыйча көрәшәм.

Йокысыз төннәрем күбрәк,
Ялгызларга эндәшәм.
Алар күңелендә берүк
Сүнмәсен, дим, соңгы шәм.

Ятим бала елмайсын, дип,
Елмаям яшь аралаш.
Менә шулай гомер үтә,
Моңа шаһит Ай-Кояш!

***

Елый-елый үсә бала,
Елый кулга алсаң да.
Елый кулларга алсаң да,
Бишекләргә салсаң да.

Керфеген дә какмый ана,
Каршылый күп таңнарны.
Башта шулай бала елый,
Бала үскәч, ана елый
Тетрәндереп җаннарны!

## ЕЛМАЯМ

Җырлап кына яшәрсең, бар,
Кәеф киткән чак була.
Сөйләшер сүз беткән кебек,
Күзләргә дә яшь тула.
    Ямь юк, тәм юк, күңел дөньям
    Айкала да чайкала.
    Җанымны да, тәнемне дә
    Боз салкыннары ала.
Елмаям: «Миндә матурлык,
Күрсеннәр әле!» -димен.
Шуңа да хәвеф -хәтәрсез
Көннәрем үтә имин.
    Кешенең җан биргәндә дә
    Елмайганы бар, беләм.
    Димәк, гомере буена
    Яшәгән ул чын күңелдән
    Елмая белү белән!

***

(«Әле һаман язасыңмы?» –дип
сорау биргәннәргә)

Бер көнем дә бушка үтми, каләм кулда,
Һаман язам шатланып та, борчылып та .
Бу бит яшәү, матур итеп яши белү,
Үз төсемдә, үз көчемдә калам, гомер
Дәфтәремә куелганчы соңгы нокта!

***

Әле генә кеше туды,
Ишетелә тәүге аваз.
Шау чәчәкле булсын җире,
Берүк күге булсын аяз.
Елар да ул, көләр дә ул,
Тып-тып басып тәпи китәр.
Гомер юлын үтә -үтә
Зур бәхеткә барып җитәр.
Әнисе бар, әтисе бар,
Туганнары, күршеләре.
Күп дуслары булыр аның,
Булыр дошман кешеләре.
Булыр аның хыяллары,
Кайгылары, шатлыклары.
Әлегә ул ак биләүдә,
Әлегә ул бәби бары.
Әле генә бала туды,
Нинди язмыш бишек эләр!
Беркем белми, ул тормышта
Ниләр кылыр, шуны беләм:
Сабый чакта елар, көләр!

## ӘГӘР ҮЛСӘМ...

Үлсәм әйтмәгез: “Котылды,
Хәле авыр иде!”, – дип.
Әйтегез сез: “Бирешмәде,
Бигрәк сабыр иде!”– дип.

Беләм, авыр көрәш белән
Үтәр гомерем юллары.
Белеп торыгыз, үлсәм дә
Юк, җиңелү булмый үлем–
Гомер бетү ул бары!

***

Елый, көлә, сабый чак бу,
Соң, кем сабый булмаган!
Елыйм, көләм, әллә инде
Сабыйлыгым узмаган!

Узмыймы соң, узган инде,
Күптән чәчләр агара.
Елыйм, көләм, димәк, шулай
Сабый чактан бер матурлык
Гел үзем белән бара.

Сабый чак белән азга да
Аерылмый икән ара.
Тик шунысы, күз яшьләре
Ачырак була бара!

## ӘНКӘЙДӘН СОҢ

Әнкәй яккан учак сүнде,
Өшемәс, туңмас өчен
Инде үзем учак яктым,
Кайгыны җинде көчем.

Учак яктым. «Ялкын белән
Яшәргә тиеш кеше.
Ялкынлы булсын сөюе!
Ялкынлы булсын эше!»

Әнкәм шулай дия иде,
Әйтеп калдырды хак сүз.
Учак яна, кызуына
Түз генә, җаным, түз, түз!

## ҖИҢӘРМЕН

Тагын җилгә каршы барам,
Алда тора авыр сынау.
Сүнмәү кирәк, мин – ялкынга,
Мин – тирәккә кирәк сынмау.

Мин бит күктә уйнаган кош,
Канатларга кирәк талмау.
Кирәк әле миңа гүзәл
Кеше булып калыр өчен,
Бу юлы да куркып калмау!

***

Әнкәй дә юк, әткәй дә юк,
Бар кайгылы күз яшем.
Ай, Кояш бар, юк ла, "Балам!"-
Диеп эндәшер кешем.

Бетәсе генә дә түгел
Миндәге авырлыклар.
Әлегә, Аллага шөкер,
Җанымда сабырлык бар.

Әткәм - әнкәм бүләк иткән
Якты дөньям – куаныч.
Күзләремнең яшен сөрткән,
Бу бердән-бер юаныч!

***

Әнкәй, бүген миңа авыр!
Исән булсаң әйтер идең:
Түз, бирешмә, кыенлыкны
Син бер түгел, меңне җиңдең!

Шулай да бит, мин әнкәйсез
Түгел идем ул чагында.
Канатларым каерылмасмы,
Калдым давыл кочагында!

Колагыма синең сүзең
Ишетелә кебек, анам:
“Үз көчеңә ышан, балам!
Үз көчеңә ышан, балам!”

## ҖЫРЛАП ЯШИМ

Җыр язарга каурыйларны
Алам күңлем канатыннан.
Җырсыз гына яши алмыйм,
Җаным шулай яратылган.

Шатлыклар да, сагышлар да
Хис-моңнарым булып таша.
Бу тормышта мин үземне,
Күрсәтәмен җырлар аша.

Җырларым саф, акны –кара,
Караны ак, дигәнем юк.
Җырлап яшим, еласам да
Башым түбән игәнем юк.

## ЕЛЫЙМ БУГАЙ

Яз иде бит әле генә,
Ямь-яшел иде тугай.
Көз җиткән, минем күңелем
Шатлыктан елый бугай.

Шулай булмыйча, өлгергән
Җимешләр авыз иттем.
Күз ачып йомган арада,
Еллар үтеп, мин бит гомер
Көземә килеп җиттем!

***

Җәй башланды, күкрәк тутрып
Сулыйм хуш исле һава.
Гүзәллекнең юк үлчәве,
Күктән җиргә нур ява.

Каеннарның тасма-тасма
Толымнарын җил сүтә.
Кошлар сайрый, моң-шатлыклар
Дәвасы җанга үтә.

Киң, иркен иген кырларын
Биектән коча тургай.
Табигатьнең бөтен яме
Бүгенге көндә бугай!

Чәчәк белән тулы ялан,
Җиләкләре баллана.
Яңа, яшел дөнья белән
Котлыйм сине, Җир-Ана!

## ҖАН БОРЧУЛЫ

Кар эри, кар суы белән
Агып китә бөтен чүп-чар.
Тукта, шулай микән әле,
Ямьсезлекнең җир йөзендә
Торып калганнары да бар.

Аракы да, тәмәке дә,
Наркотик та бар шул анда.
Бу пычракны юып алыр
Көч күрәсем килә минем,
Язның ташкын суларында!

## ЗАРЛАНМЫЙМ

Еласам да, җырласам да
Беркем дә гаеп итми.
Зарымны да түккәнем бар,
Сабыр булуга җитми!

Күзләремнең яше кибә,
Җыр да бер тынып кала.
Зарны, исә, таратырга
Җилләр күтәреп ала.

Миңа килгән авырлык бит,
Ничек авыр булмасын,
Күтәрергә кирәк, зарым
Белән дөнья тулмасын.

Дөнья матур килеш торсын,
Җир-күк җуймасын төсен.
Елап алам, җырлап алам,
Зарланмый яшәр өчен.

***

И көннәрнең матурлыгы,
Кояш көлтә нур түгә.
Жирнең өстен каплап алып
Гөлләр үсә, җиләк пешә,
Җылы җәйләр житүгә.

И төннәрнең матурлыгы,
Йолдызлары зәп-зәңгәр.
Хыялыйлар итәр төннәр,
Ут-ялкынлы хисләреңне
Тыя белмәсәң әгәр.

Киче дә бер, таңнары да,
И кошлары сайраша.
Яшәве, дим, нинди рәхәт,
Чикләре юк шатлыкларым,
Җирдән күкләргә аша.

Бу дөньга килү белән
Бәхетлемен икән ич!
Мәхәббәт сәйләннәренә
Коенып үтәм гомеремне,
Үкенерлек түгел һич!

***

Кем еласын бер кайгысыз,
Кем еласын сагышсыз!
Белмәсеннәр, күрмәсеннәр,
Яшем түгәм тавышсыз.

Кем эзләсен юатыр көч,
Кемнең хәле кем өчен!
Шөкер итәм, тешләремне
Кысарга җитә көчем!

## ИЗГЕ ЮРАУ

“Дөнья имин булсын берүк,
Афәт килмәсен илгә!”
Ананың бу теләкләре
Оча күрмәсен җилгә.

Ничек тыныч булсын күңел,
Солдат булды бит улы!
“Кошлар белән бергә китте,
Әйләнеп кайтыр юлы”.

Изге юраулары белән
Юаналар аналар.
Кайгы булып табутларда
Кайтмасыннар балалар!

## ӘРНҮ

И Ходаем, нигә ятраттың соң
Бу дөньяга кулсыз-аяксызны,
Сукырларны, чукрак, телсезләрне–
Барысы бер эшкә яраксызны!

Шатлыклардан аерып нигә кордың
Язмышларның кара пәрдәләрен?
Болай да бит синең бар тормышта
Ямьсезнең дә хәтта иң ямьсезе –
Күңелләре гарип бәндәләрең!

***

Көз, бир миңа бер матур җыр,
Ул җыр –сары яфракларда.
Ул җыр кошлар көтүендә,
Моң дулкыны еракларда.

Ул җыр аккан болытларда,
Ул җыр искән җилләреңдә.
Шул җыр булып алма пешә,
Алмагачның иңнәрендә.

Бар ул җыр, бар, әнә ул җыр,
Ул җыр иген җыйган кырда.
Бу тормышның гүзәллеген
Яңгыратыйм әле җырда.

Көз, бир миңа бер яңа җыр,
Күңелемә рәхәт булсын.
Яңгырларың күзләремә
Шатлык яшем булып тулсын.

Алтын җепләр белән чиккән
Бизәкләрең бар синең, көз.
Җырым итәр ямьнәреңә,
Берүк кенә тимәсен күз!

* * *

Изгелеген кылучылар
Рәхмәт догамны ала.
Явызларга мин дә явыз–
Алар җанга боз сала.

Бозда нинди җылы булсын,
Аңлашыладыр сүзем!
Күрәсең килсә матурлык,
Матур була бел үзең!

***

Зәңгәр күлдә чумып уйный
Сөюем аккошлары.
Әй, ул хыял, анда гел җәй,
Юк ул аның елга – күлне
Боз иткән ак кышлары.

Юк ул аның әрнүләре,
Күз яше, газаплары.
Чынбарлыкта яраттым шул,
Гомер итү язган икән
Сагынып кына бары.

***

(Илдар белән Миләүшәгә)

Күптәнмени бер -берегезгә
Үлеп гашыйк идегез,
Инде менә кавыштыгыз,
Туй балдагы кидегез.

Аерылмасын ике йөрәк,
Каерылмасын канатлар.
Арага җил-давыл булып
Керә күрмәсен ятлар.

Саф булсын сөю, аккошлар
Булып канат кагыгыз.
Кыенлыклар килгәндә дә
Һәрчак бергә калыгыз.

Аккош күле зәңгәр дулкын,
Сез йөзгән күл кипмәсен.
Бүгенге зур бәхетегез
Сезне ташлап китмәсен!

***

Илле биш ул нәрсә генә,
Юлны дәвам итәм әле.
Аллакаем насыйп итсә,
Сиксән бишкә җитәм әле.
Илле биш яшь күпмени ул,
Илле биш көз, илле биш яз!
Әле һаман һәркөн саен,
Хыялларым күге аяз.

Уйларымда үткәннәргә
Кайтмый калмыйм, күңел түзми, -
Бала чагым уйный анда,
Үсмер чагым егет күзли!
Анда минем яшьлегем бар,
Бөтен дөньям тоташ ялкын!
Шул ялкыннар җылысында
Яшимен мин, үтми салкын.

Тулы минем илле биш ел
Кайгы белән, шатлык белән.
Белмим күпме гомерем барын,
Авырлыклар булыр, беләм.
Яулап алыр үрләрем бар,
Юлны дәвам итәм әле.
Аллакаем насыйп итсә,
Туксан бишкә җитәм әле!
Дальше узып китәм әле!



***

(Илдарга)

Күтәрелсән, әгәр күккә,
Күтәрел лачын булып.
Җиргә төш, яшә тормышта
Бәхет-шатлыкка тулып.

Матур хыялларың белән
Очраш син чынбарлыкта.
Көрәшләрдә сынып калма,
Ир көче –батырлыкта!

Сакла гаиләң иминлеген,
Нык булсын корган ояң.
Җаныңны җилләр кисмәсен,
Кояшлы булсын дөньяң!

***

Ике тәлгәш җимешең бар,
Алка таккансың, миләш.
Үпкәләмә, дөресен әйтәм,
Миңа сердәш булалмыйсың,
Син миләшкәй, әле яшь.

Ни күрдең дә, ни кичердең,
Сабый гына әле син.
Мин– җиңүче давылны да,
Ә син, салкын җил иссә дә,
Үксеп-үксеп әрнисең.

Курчак белән уйнаган кыз
Яшендә син нибары.
Рәхмәт, барсың, сине күрсәм,
Миңа карап елмая күк
Балачагым еллары!

## ИСӘН ӘЛЕ АКЫЛ!

Акыл исән әле,
Кулым каләм тота,
Иҗат газабыннан
Утлар йота-йота
Язам әле, язар
Сүзләрем бар чакта.
Яктылыкны күрер
Күзләрем бар чакта.
Ямьсезлекне җуяр
Матурлык бар әле.
Авырлыкны җиңәр
Бытырлык бар әле.
Язам әле, язам,
Сөю яшәгәндә.
Язам, сандугачлы
Таллар яшәргәндә
Яшәү матур, шуңа
Язам ялкынланып.
Язам, каләмемне
Күз карама манып.



***

Шифалы, саф һава монда,
Китмик ерак диңгезгә.
Әллә каян шатлык эзләү
Гөнаһ булыр ул безгә.

Ипи исе килә кырдан,
Туярлык түгел сулап.
Әйдә, урап кайтыйк әле,
Юл үтик басу буйлап.

Анда басу кораблары
Гөр килеп тора бүген.
Бәхет кояшы нур сибеп
Балкытсын күңел күген.

Әйдә, йөреп кайтыйк әле!

***

Кемнәр шигырь яза? Оһо,
Язучылар бик күп бит!
Кемнәр шигырь укый? Юкмы?
Юк, укып тора ди, кит!

Язганнар күп, кулларыннан
Каләмнәрен куймыйлар.
Язсалар да укымыйбыз,
Язабыз – укымыйлар!

Мең- мең рәхмәт бу язмышка,
Матур заманда тудык.
Без бәхетле: Илдар, Рәми,
Әнгамнәрне укыдык!

Йә, уйлашыйк, ә кайсыбыз
Алар кебек янарбыз,
Алар кебек язарбыз?

***

Инде күптән елаганым
Юк иде.
«Син һәрвакыт шат!» –диделәр,
Күз тиде!
Тормыш бит бу, була инде
Төрле чак.
Менә бүген хәсрәтләрем
Бер кочак.
Гел кояшлы булса әгәр
Көннәрем,
Бөгелеп төшәр идемени
Гөлләрем!
Ачы яшьләр белән тулы
Күзләрем.
Тик әйтсеннәр: «Кайгыларга
Бирешми,
Елмаясың һәрчак!» -дигән
Сүзләрен!

***

Имансызлар белән тулы дөнья,
Ышанмасаң әгәр сүземә,
Алар белән әле очрашырга
Туры килер синең үзеңә.

Мин очраштым, күп әрнүләр алдым,
Йөрәгемдә тирән эзләр бар,
Минем өчен озак онытылмас
Карадан да кара йөзләр бар.

Имансыздан көтмә, күңел өчен
Бер матурлык аннан тапмыйсың.
Ерактарак булам гөнаһлардан,
Иманымны килми таплыйсым!

***

/Илдар Юзеевның якты
истәлегенә/

Көтмәгәндә килеп җиткән
Хәнҗәр-хәбәр җанны телде.
Татар илен тетрәтте бу
Авыр хәбәр: «Шагыйрь үлде!»

Шагыйрь үлде, җыр өзелде,
Моң туктады агышыннан.
Ишетелгән икән бар моң
Аның йөрәк кагышыннан.

Гомер буе гашыйк иде
Айлы төнгә, якты көнгә.
Очкан кошка, аккан суга,
Искән җилгә, үскән гөлгә.

Гашыйк иде ап-ак кышка,
Мәтрүшкәле болынына.
Хис-ялкынын кушып үрде
Каеннарның толымына.

Шагыйрь үлде! Юк, ышанмыйм,
Ул үлемне һәрчак җиңде.
Бүген исә, язлар булып,
Җиргә кабат килер өчен
Аның җаны күккә иңде!

***

Кайгы килгәч: «Түзәрме!» –дип,
Күзләремә карадылар.
Миңа карап, үзләренә
Яшәр өчен көч алдылар.

Кайгы-шатлык түгел, җанга
Газап булып тула икән.
Ә шулай да, күреп торам,
Кайгыдан да матурлыклар
Тудырырга була икән!

## КИТӘЛӘР ШУЛ

(Ярдәмчел чибәр апамны да югалткач)

Тамырыннан өзелгән гөл
Чәчәген ата алмый.
Ничекләр көтмәсен күңел,
Үлгәннәр кайта алмый.

Дөньяда үлем булмаса,
Әллә мин елар идем!
Мин бит бик күп кайгыларны
Күз яшьсез генә җиңдем.

Җир үз куенына җыя
Җандай якыннарымны.
«Сүнмәгез», – дип, бүлеп-бүлеп
Бирер идем үзләренә
Яшәү ялкыннарымны.

Юк шул, булмый алып калып,
Елап калдым бүген дә.
И, Ходаем, сабырлык бир,
Йөзәм кайгы күлендә.

***

Кабер туфрагына ятып ана елый,
Унбиш яшьлек газиз улын югалтты ул .
Бердән-берен, балакаен, кадерлесен,
Юк, үлемнән тартып ала алмады шул.

Наркотиклар белән пычрап беткән заман,
Чистарталмый икән сине күз яше дә.
Акылсызлык бит бу, бары акылсызлык,
Шуны егып сала алмый көрәше дә.

Мәк чәчәге матур булып җырда калды,
Бакчаларда үстерергә – бу куркыныч.
Ә наркоман таба аны, соң, тапкан бит,
Ана йөрәккәен телә кайгы – кылыч!

***

Кем сындырды минем каенымны,
Тәрәзәмә каршы үсә иде.
Сабый гына иде әле каен,
Йомшак җилләр сөеп исә иде.

Коча иде аны кояш нуры,
Назлый иде яңгыр тамчылары.
Тия шул ул, тия агачка да
Язмышларның үтә ачылары!

Каен елый, кеше явызлыгы
Яшь түктерә шулай гөнаһсызны.
Шундый таныш әрнү-сызланулар…
Каенкайны күргәч, күрдем кебек,
Язмыш кыерсыткан нәни кызны!

***

Кабер туфрагын кочарлар
Кулымдагы розалар .
Сөю чәчәкләре булып
Яралганнар ич алар.

Бүген шиңеп калачаклар,
Үксеп елаганнан соң .
Тирбәләчәк җанда бары
Мәхәббәттән калган моң!

## КӨТӘМ

Яңа елдан шатлык көтәм,
Шатлыкларым булачак.
Күп шигырьләр язылачак,
Яңа җырлар туачак.

Яңа елдан бәхет көтәм,
Бәхет килер, киләчәк!
Кырда шаулап иген үсәр,
Имин булыр киләчәк.

Илебездә сугыш булмас,
Кан да, яшь тә түгелмәс.
Явызлыкка чик куелыр,
Сөю кошы да үлмәс.

Яңа елдан саулык көтәм,
"Саулык – зур байлык!" – диләр.
Я, әйт дускай, Яңа елдан,
Соң, син көтәсең ниләр?

***

Йөзгә матур, бер күрүдә
Үзенә гашыйк итә.
Йөз йөз инде, күңеле матур
Булуга соң ни җитә!

Беркөн килеп шау чәчәкле
Гөлләр дә сулып кала.
Күңел тулы гүзәллегең
Тормышка, гомер юлыңа
Җуелмас эзләр сала!

## КӨЗ ЯМЕ

/К.Гәрәевага/

Гомер көзләреңә җитеп
Киләсең, сизәсеңдер.
Яшел язларыңны сагынып,
Сагышта йөзәсеңдер.

Яшьлек ямен хәтер саклый,
Уйларың әй, тирәндер.
Рәхәте дә, кыены да
Өлешеңә тигәндер!

Бураннарын ергансыңдыр,
Гөлләрен өзгәнсеңдер.
Иңнәреңдә тау булса да
Егылмый түзгәнсеңдер!

Күргәннәрең яши-яши,
Әйләнгән алтын көзгә.
Бәхетле син, күркәм, димәк:
Көзләрнең яме үзгә!

## КАЙСЫСЫН САЙЛАР ИДЕҢ?

Матурлык бар бу тормышта,
Учларыңа гына түгел,
Кочагыңа алырлык.
Ничәмә-ничә төрле ул,
Матур булып яши белү
Үзе үк таң калырлык!

Ямьсезлек тә бар тормышта,
Үзенә-үзе кул салып
Китүләр арта бара.
Син кайсысын сайлар идең?
Монда – яшәү белән үлем,
Я, чагыштырып кара!

***

Китмә, җан, китмә, тәнемнән,
Әле кирәк булырсың.
Әле син җырлы, ялкынлы
Сөю белән тулысың.

Җаннар күккә иңә, диләр,
Әйдә, гел шулай булсын.
Тик башта килгән җаннардан
Изгелек кенә тусын.

Китмә, җан, китсәң, әйләнеп
Кайтыр юл булмас сиңа.
Кояштан җиргә сибелгән
Нурдай матурлык кылганчы,
Син кирәк әле миңа.
Җан, китмә!

***

Кайгы күргән кеше көчле була,
Әлегә син шуны белмәдеңме?
Син терәгем минем, таянычым,
Иңнәреңә салдым беләгемне.

Хыял түгел тормыш, назы бик аз,
Искән җилләреннән гөлләр сула!
Шикләнмичә кара күзләремә,
Кайгы күргән кеше көчле була!

***

Кулымнан төшми каләмем
Көзләр килгән чагында.
Күрче, көзнең матурлыгын:
Каеннарда– алтын чук шәл,
Алтын алка– чаганда.

Кызыл миләш тәлгәшләрен
Кулым барып өзәлмим.
Тик шунысы, күрә торып,
Шушы кадәр гүзәллекне,
Шигырь итми түзәлмим!

Ява яфрак яңгырлары,
Тирә - ягым сап сары.
Күктә кошлар саубуллаша,
Юк, еламыйм, монысы да
Көз яме генә бары!

Көзләрдә мин сагыш күрмим,
Көзләрдә ялкын төсе.
Шушы ялкын кочагында
Мин әле тагын мең кабат
Гашыйк булырмын төсле!

## КИТМИ КАЛГАН КОШЛАРГА

Хәлләрегез ничек, кошлар?
Сезнең өчен борчылам.
Исәнлекләр теләп сезгә
Изге догамны кылам.

Быелгы кыш үтә суык,
Ничекләр көн күрәсез?
Иминлеккә юраргамы,
Зәңгәр күктә канат җилпеп,
Төшләремә керәсез!

## КИЛМӘ

Килмә, үлем, килмә бүген,
Иртәгә дә килмә әле.
Әйтерсең лә гомеремнең
Яфрак ярган гына мәле.

Килмә, үлем, бүген генә
Утырттым мин нәни каен.
Биш катлы йорт биеклеге
Булып үсәр ул, мөгаен.

Бик күрәсем килә шушы
Хыялдагы килер көнне.
"Мин яшәрмен әле!" –дигән,
Балкып торган өмет белән
Якты итәм кара төнне.

## КЕШЕ ХАКЫНДА

Яңа яуган карны шыгырдатып
Кемдер үтте, эзе калгандыр.
Бәлки әле калган эзләренә
Күңел энҗеләрен салгандыр.
Кем генә юк! Күзгә күренмәгән
Кара тапмы калды ак карда?
Күңелемә шундый уйлар килә,
Ап-ак карлар яуган чакларда.
Бүген генә яуган яңа карда
Кем эзләре калды уелып?
Яз кояшы карны эретәчәк,
Кеше хакындагы уйларымның
Бетәчәге юктыр җуелып!

## КӨТ МИНЕ

Тормыш диңгезендә җилләр көчле исә,
Өмет шәмнәреңне сүндермәсен.
Өмет белән яшә, көт син мине, көт син,
Өметсезлек сине үтермәсен.

Бүген көткәнсеңдер, иртәгә дә көт син,
Былбыллы язларны илтәчәкмен.
Ышан сүзләремә, сине, сине генә
Иң бәхетле кеше итәчәкмен.

Суык бураннардан куркып каламмы соң,
Таңнан юлга чыктым, карлар ярам.
Сөю дөньясында назга тулып үскән
Ак чәчәкләр белән сиңа барам!

## КОЯШСЫЗ

Күк йөзендә кара болыт,
Кояшсыз калды гөлем.
Боек гөлләремне күреп
Өзгәләнәм, искә төшеп,
Әнкәйсез калган көнем.

Искән җилләр болытларны
Таратыр да бетерер.
Гөлләремә көн булачак,
Ә мәрхүмә әнкәм бары
Минем төшемә керер.

***

Күл буена барып шигырь таптым,
Шигырь белән кайттым урманнан.
Кыр-болыннар шигырь бүләк итте,
Шигырь белән кердем урамнан.

Шигырьләрдә яши чәчәк кебек
Бала чагым, яшьлек елларым.
Әй, ул еллар, чиртеп-чиртеп ала
Күңелемнең нечкә кылларын.

Сагынсам да кулга каләм алам,
Шатлансам да, кайгым булса да,
Сандугачы белән яз килсә дә,
Карлар белән дөнья тулса да.

Мин кичә дә шигырь язган идем,
Шигырь белән яшим бүген дә.
Шигырь белән күрәм киләчәкне,
Юк, шигырьсез торып калмас җаным,
Ай-Кояш бар чакта күгемдә!

## КОШ

Бәргәләнә, каерылган
Канатлары, канап беткән.
Күктә уйнап очкандыр ул,
Җирдә аны бәла көткән.
Күпләр шушы юл буенда
Яткан кошны күреп уза.
Берәү, күзен сөртә - сөртә,
Яралыга кулын суза.
Димәк, аның күңел кошы
Шул халәттә, газап чигә.
Имин -аман булса җаны,
Туктап калыр иде нигә?!

***

–Көннәреңне ниләр эшләп үткәрәсең?
–Мин көрәшәм, һәрчак телим җиңәргә.
Кош булам да күтәреләм зәңгәр күккә,
Канатларым кагам каршы җилләргә.

–Балакаем, ничек үтә гомер юлың?
–Кулда каләм, язам белгән -күргәнне.
Язам җаным телгәләнеп әрнегәнне,
Чәчәкләрдән такыялар үргәнне!

–Авырдыр бит, кулларыңда көч бик аз!
–Рухи көчем белән таулар күчерәм!
Әнкәм рухы белән шулай сөйләшәм дә,
Күңелемдә рәхәт тойгы кичерәм!

## КИЧЕР

Күңел сандыгыма бикләп куйган
Серләрем юк, барысын да сөйлим.
Ни күргәнне, ниләр кичергәнне
Сөйләмәсәм, җырым итеп көйлим.

Күрсәтмичә саклап буламы соң
Дөнья кадәр булган байлыгымны.
Яшермәдем, кичер, бар да белә
Йөрәгемдә синең барлыгыңны!

## МАКТАМАМ

Дөньялары җитеш, балкып тора,
Яшәсеннәр берүк сау булып.
Туганнарым өчен җан түремдә
Шатлыкларым тора тау булып.
Кулларында эш бар, тир түгелә,
Шушы инде яшәү мәгънәсе.
Җәлләмичә көчен, тормыш өчен
Үз асылын бирә һәммәсе.
Өй эчләре тулы бәхет белән,
Бер-бер артлы үсә балалар.
Күз тидермәм микән үзләренә,
Чәчәктән дә матур бит алар.
Туганнарым белән горурланам,
Бераз гына хәтта мактанам.
Бу - урынлы. Миндә гаделлек бар,
Беркемне дә шулай, беркайчан да,
Күңел өчен генә мактамам!

## КИЧӘ ҺӘМ БҮГЕН

Шөкер, кайгым кар сулары
Белән акты,
Шатлыкларым сирень булып
Чәчәк атты.
Чәчәк исе сулап яшим
Күкрәгемә.
Канатланып күтәреләм
Күкләремә.
Бүген янә тау күтәрер
Көчтә иңнәр.
Кочагымда ак сиреньнәр,
Күк сиреньнәр!

***

Көнгә баккан нәни бөре,
Мин дә нәкъ синең кебек.
Ачылырга гына торам,
Кояш караса көлеп.

Гөл бөресе дә булам мин,
Тал бөресе дә булам.
Якты дөнья кочагына
Яшел ямь булып тулам!

Йомшак җилләр– миңа бишек,
Тирбәләм, шундый рәхәт.
Яшәүгә тагын бер адым
Ясарга көч биргән өчен,
Яңа язга зур рәхмәт!

## КӨЗЛӘР ҖИТТЕ

Өзеп-өзеп ала көзге җилләр
Ак каенның сары чукларын.
Юк, юк, көче җитми сүндерергә
Йөрәктәге сөю утларын.

Яшьлектәге кебек ялкынлы мин,
Үтмәгән дә кебек язларым.
Күзләремә баккан күзләреңдә
Әле һаман тоям наз барын.

Язлар үткән инде, көзләр җиткән,
Ап-ак карлар явар иртәгә.
Насыйп итсен Ходай, сөю белән
Гомер кышларына җитәргә!

***

Көзге төн булган ул, карлы төн,
Таң кызы түгел мин, төн кызы.
Мин туган сәгатьтә зәп -зәңгәр
Нур сипкән күкнең бар йолдызы.
Көрәшеп башланган яшәвем,
Кара төн җиңелгән, таң аткан.
Кояшы, күргәнмен, бу дөнья,
Шунда ук үзенә караткан!
Чәчләрем чал инде күптәннән,
Авырлык еш килде елатып.
Яктыга юл ярдым, юк, туймам,
Мин туймам яшәүне яратып!
Бүген дә көзге төн, яшимен
Яңа көн күрергә җан атып!

## КӨЗГЕ ЯҢГЫР

Хәерле төн теләп утлар сүнде,
Күпләр йоклый, мин дә урында.
Чыптыр-чыптыр итеп тавыш биреп,
Көзге яңгыр бии урамда.
Бүлмәм тып-тын, шул яңгырны тыңлыйм,
Өй артында гына чыбырдый.
Тәрәзәмне кагып әйтә үзе:
"Минем хакта яз бер шигырь!" – ди.
Үпкәләмә, яңгыр, күп булды, дим,
Көз турында язган чакларым.
Ә бүген мин, шатлыкларга юрап,
Килер кышның күрәм ак карын.

***

Көз үзенең алтын яллы
Тулпарын җиккән.
Җиккән генә түгел, инде
Килеп тә җиткән.
    Басу –кырлар үтеп килгән,
    Кергән урманга.
    Инде әнә килеп җитте
    Безнең урамга.
Яфракларын коя тупыл,
Сап –сары каен.
Сагыш түгел, мин ямь күрәм
Һәр яфрак саен.
    Юк, теләмим күңелемне
    Моңга төрергә.
    Өзелеп очкан яфраклар бит –
    Яшел бөрегә!
    Язсын әле ямьле язны
    Кабат күрергә!

## КӨЗ ТӨСЕ

Җил тирәкне тибрәткән дә,
Җиргә яфрак сибелгән.
Күз камаша, бөтен бизәк
Алтын белән чигелгән.

Җәйрәп яткан иген кырын
Күрәм бәхет төсендә.
Башак төсендәй матур төс
Юк ул, юк, җир йөзендә.

Көз иңенә сүрән генә
Кояш нуры сарылган.
Көз төсендә шатлыкларым,
Көз төсендә бар җырларым,
Дөнья тоташ сарыдан!

## КҮҢЕЛ БЕЛӘН АКЫЛ

–Бу дөньяны кемгә калдырырмын,
Юк бит минем улым-кызларым.
Ялкынланып яшимен дә әле,
Өелеп калыр сүнгән кузларым.

Ай-Кояшны кемгә калдырырмын?
–Син борчылма әле, әй, күңел.
Тыңла җавабымны: «Бу дөньяны
Яшәвенең кадерен белгәннәргә
Калдыруы һич тә җәл түгел!»

## КҮҢЕЛ ТҮЗӘ

Күктә, катлам-катлам булып,
Кар болытлары йөзә.
Җил туктаусыз тирәкләрнең
Сары яфрагын өзә.
Салкынаеп бара көннәр,
Көз күрсәтә үз көчен.
Кояшны көтә чәчәкләр
Тик бер җылыныр өчен.
Очар кошлар бүген әзер
Чыгарга ерак сәфәр.
Күңел түзә, үксеп-үксеп
Елар гына иде, килер
Җәйләр булмаса әгәр.

***

Кыенсынма, сөйлә әле,
Җиде ят, диеп торма.
Яшермә син карашыңны,
Сүзеңне читкә борма.

Сагыш белән мөлдерәмә,
Күңел күлең бар, беләм.
Булган кичерешләреңне
Уртаклаш минем белән.

Җилләргә сипмәм сереңне,
Үскән гөлгә сөйләрмен.
Синең дә күргәннәреңне
Бер җыр итеп көйләрмен.

## КУНАК КӨТӘМ

Дөрес, сынадым: «Саескан,
Чыгырдаса, кунак килә», –
Диеп әйткән халык сүзен.
Ипи сыныклары белән
Саесканны кунак итәм,
Сыйладым мин башта үзен.
Инде менә кунак көтәм,
Тәрәзәдә ике күзем,
Син кил иде!

***

Куркытырга дип кошларны,
Күккә төзәп аталар.
Ни гаебе бар кошларның?
Алар яңа җырлар белән
Туган җиргә кайталар.

Күрәзәче булмасам да,
Хак булачак сүзләрем.
Юк, чир алып кайтмый кошлар,
Җаннарына курку салып,
Рәнҗетмәгез үзләрен.

Урау-урау юллар табып,
Кайтып җитәрләр алар,
Әгәр кошлар кайтмый калса,
Яфрак ярырмы тирәкләр,
Яз булалырмы язлар?!

***

Мамык шәлдән җылы эзлим,
Фатир суык, өшетә.
Авылымда гомер иткән
Чакларыма ни җитә!

Өебез "май" кебек иде,
Шәл бөркәнү кая ул!
Шәһәрдә салкын көз ае...
Сагынам сине, авыл!

**КУРКЫТТЫ!**

Ирләрдән дә болайрак
Сүгенәләр бичәләр.
Сүгенү – ул нәрсә генә -
Чәкештереп эчәләр.
Күзләренә эрен каткан,
Ул чәче, ул өс-башы!
Менә шундыйларның берсе
Очрады миңа каршы.
Үтеп кенә китсен иде,
Китәме соң, туктады.
Яңалыгын сөйләп китте:
"Мине, ди, ир тукмады!"
"Әйбәт булган!" –дигән идем,
Акайтты да күзләрен,
Мине тиргәп, тезде генә
Шаккатарлык сүзләрен.
"Минем хакта шигырь язсаң!" –...
Диеп, бармак янады.
Курыкмадым. Хәлакәткә
Бара тормыш, шуны күреп,
Йөрәк кенә канады.

## КҮЧЕНГӘНДӘ

Яңа йортка кереп киләм,
Дулкынлана күңел –диңгез.
Әйтә кебек шушы мәлдә
Ерактагы туган нигез:

–Шатлыкларың таудай булыр,
Коштай канат кагынырсың.
Тик син мине оныталмассың,
Гомер буе сагынырсың!

Яңа йортның тәрәзләре
Балкып тора бүлмә саен.
Шатлыгым –бер, сагышым –мең,
Сабырлыклар бир, Ходаем!

***

Мәхәббәт –ул синең карашларың,
Мәхәббәт –ул синең тавышың.
Мәхәббәт –ул айлы, йокысыз төн,
Мәхәббәт –ул минем сагышым.

Сөйгән өчен елыйм үксеп-үксеп,
Сөю белән табам юаныч.
Мәхәббәтем минем мең газаплы,
Мәхәббәтем бирә куаныч.

Сөю килеп –җанны ялкын итә,
Язлар килеп –җирне яшәртә.
ЯрАтканга күрә үлү –гөнаһ,
Чын ярату көче –яшәтә!

***

Күңелемне ачып кара әле,
Булыр микән анда берәр тап.
Ярма бөртегедәй кара тапны
Кара әле, кара, эзләп тап.

Юк, тапмассың, көчем бар бит әле,
Мин калмадым әле җиңелеп.
Күңелем сафлыгына тап булырдай
Явызлыкны барам гел җиңеп!

## МАТУР ЯЛГАН

Урамга чыккач танышлар:
–Үзгәрмәгәнсең, –диләр.
Кат-кат әйтәләр: "Син әле,
Элекке кебек чибәр!"
Кайсысы әйтә: "Тик менә
Чәчеңне буяп җибәр.

Теш тә куйдыргансың икән,
Күзлек киясеңдер ул?"
Үзләре әйтеп тора бит,
Үзгәрмәү буламы шул!

Әй, ул телме, тел сөяксез,
Алар сөйли, мин сөйлим.
Тик шунысы, дөресе шул:
Ялган сөйләүне сөймим.

Гомерем юлы чакрымнарын
Санап барам –аз түгел.
Тик, ни хикмәт, танышларның:
–Үзгәрмисең, – диюенә
Ышанып куя күңел!

## МАКТАРГА ЯРАТМЫЙМ

Кайберәүләр: «Байлыгымны
Күрсеннәр!» -дип кунак җыя.
Дөньясына шаккаталар,
Шатлыгыннан акылын җуя.

Берәүләрнең күңелләре
Тулы була байлык белән.
Мин кунакка аңа барам,
Мактау кирәкмәвен беләм.

## КЫШКЫ УРМАНДА

Булмаса да җиләк – җимешләрең,
Бүген синдә үзгә матурлык бар.
Кышкы урман: әнә, сикереп-сикереп,
Тиен уйный, агач ботагыннан
Тасма-тасма булып сибелә кар.

Тук-тук итә тукран, чыркылдашып
Очышалар әнә Сарытүшләр.
Кыш мул карлы, өшемәсеннәр, дип,
Имән, каен, чыршы төпләренә
Катлам-катлам карын янә түшәр.

Кышкы урман, синең кочагыңа
Саф һаваңны сулый-сулый керәм.
Күңелемдә бары шатлык кына,
Иңнәреңдә яткан бәс ктысын
Язылачак шигырем итеп күрәм.

## МАТУРЛЫК ЯШӘСЕН!

Үләмдер инде, димим, юк,
Әле иртәдер кебек.
Авырумын, соң, булса соң,
Әнә, болытлы көндә дә
Чәчәкләр тора көлеп!

Яшәү мәңгелек түгел бит,
Соңгы минуты булыр.
Куркам, үләм инде, диеп
Уйнап әйтсәм дә, дөньяда
Бөтен матурлык сулыр!

## МАТУРЛЫГЫҢ КҮРЕНЕР

Зарлануның файдасы юк,
Юк тыңлый белүчеләр.
Булса-булыр хәлең күреп,
Егылып көлүчеләр.

Күз яшеңне түгеп түгел,
Җырлап яшәргә кирәк.
Салкын җилләр искәндә дә
Яфрак яра бит тирәк!

Бөгел-сыгыл, сынма гына,
Матурлыгың күренер,
Тамырыңнан шыткан гөлләр
Гел кояшка үрелер!

***

Матур хыял, тормышка аш,
Син ул минем киләчәгем.
Җем-җем энҗе -мәрҗәннәрдән
Нәкышланган күрәчәгем.

Матур хыял, тирәгемә
Кил син бәхет кошым булып.
Назлы җилле яз булып кил,
Кил ак карлы кышым булып.

Матур хыял, чынбарлыкта
Очрашыйк без, ялган булма.
Ялкын булып сүнмә, хыял,
Чәчәк булып берүк сулма!

***

Мин үлүдән куркам, үлсәм,
Байлыгымны таларлар
Имансызлар ерак йөрми,
Янәшәмдә бар алар.

Әле исән чагымда ук
Керештеләр урларга.
Шигырьләрем инде барып
Керде пычрак кулларга.

Саф күңелем энҗеләрен
Шыгъри юлларга тезәм.
Язам халкым укысын, дип.
Үлмәс өчен, килгән барлык
Авырлыкларга түзәм.
Мин үлүдән куркам, үлсәм ...

# МИН ЫШАНАМ ЯҢА ЕЛГА

Мин ышанам Яңа елга,
Ышаныгыз әле сез дә.
Ризык булыр өстәлләрдә,
Бәйрәмнәр күп булыр бездә.

Талларына кайтыр кошлар,
Таңнар атар бәхет булып.
Тырышканнар яулар үрне,
Сөю гөле калмас сулып.

Туй күлмәге кияр саф кыз,
Егетләр чын батыр булыр.
Ятимнәрнең саны артмас,
Тормышыбыз матур булыр.

Җиребездә иген үсәр,
Яңа йортлар чыгар калкып.
Сугыш булмас, бу шатлыктан
Көн дә кояш торыр балкып.

Мин ышанам Яңа елга,
Бай булыр ул бәбиләргә.
Хөрмәт булыр күпне күргән
Бабайларга, әбиләргә.

Авырлыклар булмый булмас,
Бирешмәбез, шуны беләм!
Ә бүгенгә – Яңа елны
Каршылыймын догам булган,
Шушы яңа җырым белән!

## МИН - ЧАЯН

Кадалдың кара ук булып,
Җанымның ярасы бар.
Тешне кыстым, азмы, күпме,
Янәшә барасы бар.
"Куркыттым!" –диеп уйлама,
Башымны түбән имим.
Чаян йолдызлыгыннан мин,
Әлегә юк, юк, тимим.
Сабырлыгым бер сыначак,
Мең тапкыр үкенерсең.
Мин түгел, син җиңелгәнне
Менә шунда күрерсең!

***

Мин дөньяга килгән җир бу,
Йорт-нигез юк, бушлык калган.
Гөлләр үскән ихатаны
Кычытканнар басып алган.

Йорт урынында гади койма,
Тирәкләрне кемдер кискән.
Мин киткәч тә инде күпме,
Сулар аккан, җилләр искән!

Шушында мин, нәкъ шушында
Тәпи бастым, чәчәк аттым.
Минем өчен газиз җир бу,
Сагынуларым белән кайттым.

Фотоаппаратны алам,
Күзләремә яшем тулып.
Соңгы чара, туган нигез
Кала фотосурәт булып!

***

(Нажиягә)

Илле биш яз килде сиңа
Чәчәк -гөлләре белән.
Иңнәреңнән кочты җәйләр
Җылы көннәре белән.

Алтын көзләр, ап-ак кышлар
Синең үткән юлыңда.
Шөкер итеп яшә берүк–
Бәхет кошың кулыңда.

Каптың татлы алмаларын,
Каптың ачы чиясен.
Күңелең тулы җыр булганга
Авырлыкны җиңәсең.

Тормыш давылларына, юк,
Бөгелмәссең, мин беләм.
Яшә тагын илле бишне
Шушы матурлык белән!

## МИНЕМЧӘ ШУЛАЙ

Шау-гөр килеп үтә туйлар,
Киленнәр төшеп тора.
Авылны үз итмиләр шул,
Бу кошчыклар очып китеп,
Чит талга оя кора.

Мескенләнеп бара авыл,
Тормышның яме китә.
Ямьне кире кайтарырга
Авыл өе матчасына
Бишекләр элү җитә!

***

Музей нигә кирәк? –дигән
Соравыңа җавап әзер:
Бел, элекке үткән тормыш
Музейларда яши хәзер.
Ай-һай тырыш булган халык,
Кирәк өчен тирен түккән.
Җирен сөргән, урак урган,
Киндер суккан, чиккән, теккән.
Бәби тугач, өй түренә
Үзе ясап бишек элгән.
Сукыр лампа яктысында
Чабатасын үзе үргән.
Мин санарга җыенмыймын
Музейдагы әйберләрне.
Хөрмәт итеп искә алам
Бабайларны, әбиләрне.
Син, бүгенге яңа кеше,
Тыңла, музей тарих сөйли.
Бел син, үткән заман халкы
Синең белән бергә яши
Үз моңнарын көйли -көйли!

*** (Рәфискә)

Күзләреңә карыйм кебек соңгы тапкыр,
Соңгы тапкыр тарыйм кебек чәчләреңне.
Иреннәрең үбәм кебек соңгы тапкыр,
Моннан соң гел түгәрмен күк яшьләремне.

Сине сагынып соңгы тапкыр килгәнмен дә,
Соңгы тапкыр саубулашып китәм кебек.
Юк, бу күңел нечкәлеге, ә дөресе:
Сөю чирдән көчлерәк ул, мин бит сиңа
Сөюем белән яшәү бүләк итәм кебек!

## МОҢ ӨЗЕЛДЕ

(С. Рәвилгә)

Кулларында гармун иде,
Моңы барны җырлатты.
Дәртлеләрне биетте ул,
Сагышлыны елатты.

Тал-тирәкләр яфрак ярды,
Бүә буе ямь-яшел.
Сандугачларга кушылып
Гармун җырлый иде гел.

Гармун өнсез калды бүген,
Кайгылы яшен түгә.
Җырламый да, җырлатмый да
Утыртсалар да түргә:
Хуҗасы керде гүргә.

Моң өзелде, юк юк, өмет
Өзелә торган түгел.
Гармунчының улы калды,
"Инде ул гармун уйнатыр!" –
Дип, өметләнә күңел.

## ЕЛАДЫМ

Яшереп булмый шатлыкны,
Елмайдым –кояш чыкты.
Миндәге көч кайгы кадәр
Кайгыны бәреп екты.

Еладым –җемелдәп торган
Чыкка төренде гөлләр.
Минем шулай шатлыктан да
Бар ул елаган көннәр!

## ӨЧ ТЕЛ

Исәнмесез! Һаумыһыгыз!
Здравствуйте! – Бер үк сүз.
Матурдан да матур булган
Бу өч тел дә миңа үз.
Өч тел беләм, юк, берсен дә
Сайрар кошка алышмыйм.
Сөйләсәм дә, көйләсәм дә
Былбыллардан калышмыйм.
Ипи тәмен белгән кебек,
Тәмен беләм өч телнең.
Гомеремә җитәр яме,
Байлыгы бу күңелнең.

***

Нур - кыллардан оя үреп,
Гомер иттеләр парлар.
Балалар да үсте, бик тә
Бәхетле булды алар.

Кайгы ул җиңелер иде,
Монда бит, үлем килде.
Таралды да бетте дөнья,
Мал-мөлкәт хәлаль иде.

Балкып торган яшәү уты
Сүнеп кала икән шул.
Дөнья кала, шунда түккән
Көчең кала икән ул.

Бер уйласаң бар да кала
Чүп-чар өеме булып.
Ташландык йорт-ихатага
Карап тора күрше хатын,
Күзләре яшькә тулып.

***

Моң белән тулы күкрәгем,
Җырлаганым юк күптән.
Кычкырып җырлап утырган
Чакларым күптән үткән.

Гашыйк булгач җырладым мин,
Җырладым сөенгәндә.
Җырга әйләнә бар дөньяң
Сөйгәндә сөелгәндә.

Ишетеп калсам яңа җыр,
Гармунны ала идем.
Бар моңымны, сагышымны
Шул җырга сала идем.

Бармаклар инде басалмый
Гармун басмакларына.
Инде яшәп яткан чагым,
Шөкер итеп барына.

Юк, мин җырдан аерылмадым–
Җанда саклыйм үзләрен.
Ялкынланып иҗат итәм,
Язам җырның сүзләрен!

***

Сине чәчәк, диеп була – гүзәлсең,
Кояш, диеп була сине – җылысың.
Сине йомшак җил, дип була – назлысың,
Былбыл, диеп була сине – җырлысың.

Тал-чыбыктай бөгелмисең –горурсың,
Сине батыр, диеп була –сабырсың.
Син –хатын-кыз, син – сөйгән яр, син –ана,
Иманыңа тугры булып калырсың!

***

Ни генә юк бу тормышта:
Югалту бар, табыш бар.
Ярату бар, яратмау бар,
Җиде ят бар, таныш бар.

Ут бар, су бар, көн бар, төн бар,
Туу бар һәм үлү бар.
Үксеп-үксеп елаулар бар,
Шатлыклардан көлү бар.

Җиле исә, гөле үсә,
Яңгыры бар, кары бар.
Буш буламы күкрәк –савыт,
Моңы барның зары бар.

Бар изгелек, бар явызлык,
Куркаклар бар, батыр бар.
Бар ямьсезләр, эше белән
Күркәм булган матур бар.

Бар үрләре, бар упкыны,
Алулар бар, кушу бар.
Бу тормышны түм -түгәрәк
Итә менә шушылар.

Туктыйм инде, күпкә китте,
Санарга да, санарга!...
Яши-яши шуны белдем,
Кирәк икән йөрәк шушы
Тормыш өчен янарга!

## НӘРСӘ БӘХЕТ?

Ак-караны аера белсәң,
Туктап калмый үрләр менсәң,
Көрәшләрдә җиңә алсаң,
Суга төшеп батмый калсаң,
Сине сөйсә сөйгән кешең,
Татлы җимеш бирсә эшең,
Өстәлеңдә булса икмәк,
Илең-көнең имин, димәк!
Иңнәреңдә канат тойсаң,
Күңелләргә бизәк койсаң,
Һәр адымың булса алга,
Син бәхетле, шуны аңла!

***

Нәкъ менә, бүгенге кебек,
Җиргә кар төшкән булган.
Көтеп алган шатлык булып
Гаиләдә бала туган.
Дөньяга кыз бала килгән,
Елап биргән тавышын,
Кендек әби әйткән алдан
Күреп аның язмышын:
"Туса да төнге сәгатьтә,
Якты үтәр юллары.
Күрәчәген күрми булмас,
Үз өлеше, бәхет кошын
Тотып алыр куллары".
Язмышы ачы җимешле
Кеше турында сүзем.
Тешләрен кысып, елмаеп,
Бу көненә шөкер иткән
Әнә шул кыз – мин үзем!

***

Наиләгә бүген – бер яшь,
Матур инде, гел курчак!
Матур гына буламы соң,
Акыллы да булачак.

Өч-дүрт яшькә җитсен әле,
Су сибәр ул гөлләргә.
Гөлләр белән бергә үсәр
Үрелеп якты көннәргә.

Әтисенең, әнисенең
Булыр ул зур шатлыгы.
Бүген бәйрәм, Наиләгә
Бәхет алып килсен минем
Уйларымның аклыгы!

## ӨМЕТ

Әйтелгән изге китапта:
«Исереккә бирмә кул!»
Исерек хатын –кыз күрсәм,
Җирәнәм, әйтерсең ул
Пычрата бөтен дөньяны,
Кояшның нурын каплый,
Баткакка әйләнә күлләр.
Аклык-сафлыкны тапмый,
Күршедә бер хатын эчә,
Күрәсем килми йөзен.
Төзәтсен иде ялгышын,
Тиң итеп ал розаларга
Күрәсем килә үзен!

## ТУЙ АТЛАРЫ САГЫНДЫРА

Пар ат җигеп, дугаларга
Элеп пар кыңгыраулар
Юк инде ул, элеккечә
Урамнардан ураулар!

«Туй атлары килә!» -диеп,
Шатлыклы хәбәр салып,
Йә, җиңгидән, йә, җизнидән
Күчтәнәч, бүләк алып,

Шау -гөр килеп йөгерешкән
Балачак онытылмый.
Авылымда туйлар була,
Тик анда атлар булмый.

Бизәлгән машиналарны
Үз итә хәзер заман.
Мин исә, пешкән җиләктәй
Кыз сыман, кыңгырау таккан
Атларны көтәм һаман.

## СҮЗ КӨЧЕ

Нәрсә соң ул шигырь? Шигырь – сөю,
Сагыш, кайгы, шатлык.
Үткәннәр бар анда, киләчәк бар.
Якты өмет, хаклык.

Утлар да бар анда, газап та бар,
Шигырь булмый сүзсез.
Шагыйрь үзе үлә, шигырь үлми,
Җан авазы– шигырь, бу дөньяда,
Бары ул үлемсез!

***

Өй буена агач утырталар,
Матурлык һәм шатлык артачак.
Яз яктысын салып иңнәренә
Алмагачлар чәчәк атачак.

Аңкып торыр һава хуш ис белән:
Шомырт та бар анда, сирень дә.
Кызыл миләш, балан тәлгәшләре,
Янып торачак көз илендә.

Бу агачлар шаулап үскән саен,
Гел яшисе килеп торачак.
Алсу таңнар сызылып аткан чакта,
Миндә яңа җырлар туачак.

Җилләр генә сөеп иссен берүк
Агачларның яшел бөдрәсен.
Былбыл кунып сайрар ботакларга
Явыз куллар үрелә күрмәсен!

***

Таш юлда күгәрчен канаты,
Кан табы, тәгәрмәч эзләре.
Якында бер ала күгәрчен,
Сагышлы яшь тулы күзләре.

Кошкайлар җим чүпләп йөргәндә
Булган бу фаҗига. Күрәчәк!
Дускаен югалткан күгәрчен,
Ялгызы боз булып туңачак,
Ялгызы утларга керәчәк!

## ӨЗЕЛГӘН ЧӘЧӘКЛӘР

Ни галәмәт, әле һаман
Җир йөзендә кан коела.
Әле генә булган хәлдән
Өзгәләнә җан, кыела.

Террорчылар бер гөнаһсыз
Бәндәләрне кырып салды.
Исәннәрнең күңелендә
Тау-тау булып кайгы калды.

Гафу итеп буламы, юк,
Явызларның шакшылыгын.
Челпәрәмә иттеләр бит
Сабыйларның зур шатлыгын.

Гөлләмәләр тоткан килеш
Күпме бала җансыз калды.
Алар белем мәктәбенә
Тик бер адым ясый алды.

Бу өзелгән чәчәкләрне
Терелтү юк, мөмкин түгел!
Беслан җире фаҗигасын
Уксеп искә алыр күңел.

Мәктәпкә дип китеп барган
Балаларны карап калам.
Хәвефләнәм, афәтләрен
Күрсәтмәче берүк, Аллам!

***

/Рима Фәми кызына/

Яшәү уттан тора икән,
Балкып янасың.
Тормыш төрле утка сала
Адәм баласын.

Янып эшләү, янып сөю –
Ул синең язмыш.
"Гомеркәем үтте!" – диеп
Уфтанма ялгыш.

Гомер судан тора икән:
Аккан да киткән.
Барган юлың адаштырмый–
Бәхеткә илткән.

Гел алтын да көмеш икән
Гомернең көзе.
Синең алдыңда шул гүзәл
Дөньяның үзе!

## САГЫНАМ

Күзен йомды әнкәй, кояш йөзен
Каплап алды болыт.
Торып калдым давыл кочагында,
Калдым ятим булып.

Сабый түгел идем, үскәч кенә
Мин әнкәйсез калдым.
Нык булсам да тормыш салкыннарын
Җанга байтак алдым.

Ничә яшьтә булма –сабыйсың син
Исән чакта ана.
Әнкәй назын сагынып үксимен мин –
Чәчләре чал бала!

## РӘХМӘТ, ЯҢА КӨН!

Рәхмәт сиңа, бүгенге көн:
Кояшлы булдың.
Чикләре юк, шатлык булып
Күңелемә тулдың.

Соң булмаса, булмый инде
Куллар, аяклар.
Өстәлемдә ипикәем,
Ашым, чәем бар.

Якыннарым исән-саулар,
Күршеләр имин.
Якты көн шуңа да сиңа
Зур рәхмәт, димен.

Аллага шөкер, ялгызлык
Мине өшетми.
Үкенү, әрнү, сагышлар
Җанымны өтми.

Дустым белән очраштырдың,
Рәхмәт, яңа көн.
Бүген дөньям түп -түгәрәк,
Бәхетем Бербөтен.

## САБЫР ИТ

/ Язмышташым Җәмиләгә /

Мин дә әнкәйсез калдым бит, сабыр ит,
Күрәчәкне күреп газап чигәбез.
Гомер буе көрәшәбез туктамый,
Кайгыларны без барыбер җиңәбез!

Безнең язмыш яраланган кош кебек,
Канга батып күтәрелдек күкләргә.
Ныклы терәк булды безгә әнкәйләр,
Югалтсак та без аларны, тормышта
Матур үрнәк булып калыйк күпләргә!

## РӘХМӘТ СҮЗЕМ

Ярдәм сорап эндәшәбез
Авырулар, өлкәннәр.
Тән дә, җан да бергә өши,
Болытлы безнең көннәр.

Ярдәмчесез барып булмый
Җилгә -давылга каршы.
Мең-мең шөкер, ярый әле
Син бар, шәфкать туташы.

Сез бар, шәфкать туташлары,
Сездән җылы көтәбез.
Сездән күңел ярасына
Дәва өмет итәбез.

Изгелектән яралгансыз,
Буласыз һәрчак түзем.
Сезгә барып җитсен бүген
«Зур рәхмәт» дигән сүзем!

## СИН ИДЕҢМЕ?

Утым озак янды, яздым,
Хисләр ташып түгелде.
Сагышларның сары бәсе
Сарган иде күңелне.

Төне буе шигырь яздым,
Сагындым ич мин сине.
Тәрәзәдән әллә син ул
Күзәтеп тордың мине?

Мин–сине, син мине булмый,
Соң, кемне кемнәр күзләр!
Яңа яуган кар өстендә
Уелып калган эзләр.
Син идеңме?

## РӘХМӘТ ӘЙТӘМ

Елый-елый: “Әнкәй мине
Ник таптың соң!” -- димәдем.
Авырлыклар чутсыз булды
Башым түбән имәдем.
Бүген дә бит җиңел түгел:
Чирем белән көрәшәм.
Үземдәге булган көчне
Башкаларга өләшәм.
Минем кебек елмайсыннар,
Яшәүнең ямен табып.
Беркем боекмасын, күңел
Канаткайлары талып.
Мин бит үзем гомер буе
Гүзәллеккә омтылам.
Миңа шундый матур яшәү
Бүләк иткән әнкәемә
Рәхмәт догамны кылам.

## СӨЮ КӨТКӘН ЧАГЫМ

Болыннарда бергә йөргән чакта,
Минем өчен гөлләр өзмәгез.
Сагыш белән тулы күңелемә
Дәва булыр сүзләр эзләгез.

Юатулар көтеп тилмергәндә,
Ялган сүзләр берүк тезмәгез.
Хыяллардан мине аермагыз,
Өметемне зинһар өзмәгез.

Сөюемне көтәм, бәлки әле,
Хаклык бардыр әйткән сүзләрдә.
Кайнар сөю белән килә, диләр,
Язлар гына түгел, көзләр дә.

***

Тамчы тама, ага гөрләвек,
Ерыладыр инде буа да.
Чоп-чуардыр тупыл башлары:
Кара карга килә бу айда.

Бакчадагы куак -тирәкләр
Уйларымда бар да тереләр.
Их, тәмледер һава, мәле шул,
Таң чыгында бүртә бөреләр!

Элеккечә язлар авылга
Бөтен яме белән киләдер.
Бикле йортның ишегалдына
Кайтып әйләнәсе килә бер!

***

Сату итү чире белән
Яшәгәндә бу заман,
Мин бер үзем читтә торып
Кала аламмы һаман!
Китап сатам. Яшел тышлы
Китапларда – "алтын"нар.
Алтын гына буламы соң,
Анда сүнмәс ялкыннар.
Минем йөрәк җырларым ул,
Китап булып сатыла.
Матур түгел, әйтерсең лә,
Җаныма ук атыла.
Борчулымын, ни әйтсәң дә,
Бүгенге көн, әй, яман.
Китап, җыр-моң, нәрсә генә,
Бу бит шундый анасы үз
Баласын саткан заман!

## САГЫШЛЫ ТӨН

Мин авылда, ут бар, ишек
Ачык, була керергә.
Кердем өйдә булган бөтен
Матурлыкны күрергә.

Җылы, якты, тәрәз саен
Гөлләр шау чәчәк аткан.
Әнкәй дә бар, сеңелем дә,
Әткәй дә эштән кайткан.

Өйдә тәмле булып пешкән
Ипи исе; аш исе!..
Юк ла, болар бар да ташып
Торган сагынуым хисе.

Бик еш шулай сагыну алып
Килә миңа төннәрем.
Ни хәлләр итәрсең, язмыш!
Ташландык йорт булып яши
Иң бәхетле көннәрем!

***

Елавыннан, хәтта, көлүеннән
Танып була ятим баланы.
Кемнәр генә, кайчан әрнетмидер,
Җанындагы тирән яраны.

Ятим бала ятим булып кала,
Үз итсә дә чит-ят ояны.
Кәккүк –ана, хаталарың белән
Син тормышны тәмам ямьсезлисең,
Пычратасың якты дөньяны.

## САГЫНМЫЙМ

Юк, яшьлекне сагынмыймын,
Мин әле дә карт түгел.
Гомер юлын күп үтсәм дә
Унҗиде яшьтә күңел!

Утте димим гомеремнең
Шау чәчәкле айлары.
Үзгәреш юк, чәчләр генә
Төсен үзгәртте бары!

Каләмем дә кулда һаман,
Язам сөю хакында.
Хыяллар нур булып балкый,
Йөрәк тоташ ялкында.

«Иркә апа!» диләр мине
Сеңелемнең оныклары.
Картаймадым, алтмышыма
Якынаямын бары!

***

Сугып авырттыра алмам,
Тиргәүнең дә көче җитмәс.
Курык минем күз яшемнән,
Рәнҗү-каргыш ерак китмәс.

Бугазыңнан буып алыр,
Хатаң өчен үкенерсең.
Үкенүләр – авыр газап,
Килеп гафу үтенерсең.

Төзәлсә дә күңел ярам,
Юк, җуелмас түккән караң!

## СОҢГЫ ЧӘЧӘКЛӘР

Соңгы чәчәкләргә карап,
Тирән уйларга талдым.
Буш калмадым,бу көздән дә
Күңелемә моң алдым.

Инде кояш нуры сүрән,
Җылы җитми гөлләргә.
Их, әйләнеп кайтып булса
Иде җәйге көннәргә!

Тиздән кар да төшә башлар,
Чәчәкләрдә күзләрем.
Сагынусыз яшәп булмас,
Сөеп калыйм үзләрен!

Әбекәйләр, күрәм сезне
Соңгы чәчәкләр итеп.
Рәхмәт сезгә, чәчәк төсен
Югалтмыйсыз килгәндә дә
Гомер чигенә җитеп!

***

Суз кулыңны, ярдәмеңә мохтаҗмын,
Тик изгелек булсын синең күңелдә.
Әллә ниләр көтмим синнән, нибары
Ай –Кояш бул минем күңел күгемдә.

Син чит кеше, ләкин, сиңа ышанам,
Күзләремнең яшен сөртә алырсың.
Күп кирәкми, тик хәлемне аңлый бел,
Шулчак матур кеше булып калырсың.
Суз кулыңны!

***

Сирень, әле син кечкенә,
Чәчәкләрең булмады.
Килер язлар шатландырыр,
Юк, өмет-гөл сулмады.

Шау чәчәкле булырсың син,
Хуш ис торыр аңкылып.
Синдәге бар матурлыкка
Һәркем карар таң калып.

Сирень, сине авылыбыздан
Китерттем мин шәһәргә.
Ходай насыйп итте безгә
Янә бергә яшәргә.

Тамырларың чит туфракта,
Кичер мине, гафу ит.
Кайда гына яшәсәк тә
Бер үк кояш, бер ай бит!

Авылымның бер төсе син,
Әй, сиренем, сиренем.
Сагынусыз гына булмый,
Юанычым бул минем!

***

Тәрәзәмә озын челтәр элгәнем юк,
Ник карыйм ди яктылыкка пәрдә аша!
Күңелемне нуры белән иркәләгән
Кояш белән аралар бит ераклаша.

Якты кирәк, гөлләремә якты кирәк,
Гөлләр белән тулы минем күңел бакчам.
Арынасым килә кайгы -хәсрәтемнән,
Яшькә тулы күзләремне көнгә ачам.

***

Сереӊ дә бар, моӊыӊ да бар,
Сабырлыгыӊ –сыналган!
Кыюлыгыӊ, тырышлыгыӊ
Зур үрләр яулап алган.
Син сөясеӊ, синеӊ сөю
Ялкыннары мәӊгелек.
Таш яуса да горур була
Беләсеӊ син иӊ элек.
Хатын –кыз син, бу дөньяныӊ
Бер гөнаһсыз гүзәле.
Чын йөзеӊә тиӊ булырлык
Матурлыклар юк әле!
Кояштан да җылыраксыӊ,
Хатын-кыз– син, син– ана!
Синеӊ күӊел сафлыгыӊнан
Ал таӊнар якты ала.
Хатын-кыз– син чәчәкле гөл,
Син ул, син– бөреле тал.
И Хатын-кыз, тормышта да,
Минем хыялымда кебек
Кал син, тапсыз булып кал!

## ТӘМ

Шигырьдә бар ипи тәме,
Бал-май тәме, сөю тәме.
Шуӊа да ул – рухи азык,
Тук булуда яшәү яме.

Шагыйрь генә белә торган
Тир тәме бар шигырьләрдә.
Бәхетледән бәхетлерәк
Итеп тоям мин үземне
Шигырь туып килгән мәлдә.

## СУГЫШ БЕТТЕ

Сугыш бетте, ишетелми
Ату тавышлары.
Ә йөрәктә яши аның
Кайгы-сагышлары.

Сугыш бетте, иркен сулыш
Алыр көннәр җитте.
Әй, ул сугыш, бик күпләрне
Гарип, ятим итте.

Сугыш бетте, асыл кошлар
Сайрый иртә-кичен.
Кемнәр аңлар тол хатынның
Утлар тулы эчен!

Сугыш бетте, яз елмая,
Үсә матур гөлләр.
Онытырлык түгел, үткән
Ул дәһшәтле көннәр!

Сугыш бетте, алтмышынчы
Тапкыр бәйрәм килде.
Җиңү-шатлык, югалтулар–
Бәгырьләрне телде!

Сугыш бетте, җиңеп кайткан
Солдатларга дан! Дан!
Күктә ап-ак күгәрченнәр,
Сакласыннар алар җирне
Яңа сугышлардан!

## СӨЮ КАБУЛ ИТ

Юмартлыгым – көздән,
Матурлыгым – гөлдән.
Күңелемдәге якты
Аккош йөзгән күлдән.

Горурлыгым – таудан,
Җитезлегем -- җилдән.
Көчем – давыллардан,
Сабырлыгым – Җирдән .

Өметләрем – таңнан,
Кыюлыгым – уттан .
Яралганмын икән
Бөтен матурлыктан!

Моңым, кайгыларым,
Шатлыкларым – синнән
Тормыш, кабул итеп
Сөю ал син миннән!

***

Тормышта күп утлар йоттым,
Ташлары да йотылган.
Минем күңел йомшак иде,
Бәгыремә таш тулган.

Күргәннәрең хаттин ашса,
Үзгәрәсең икән шул!
Назлы җилләр булып исмәм,
Минем янда бик сак бул.

«Кара, нинди усал!» –диеп,
Гаепләрсез, мөгаен.
Юк, башымны иеп тормыйм,
Кемдер таш бәргән саен!

***

Төнге яңгыр– ялгызларның
Үксеп түккән күз яше.
Әй, күп бит ул бу дөньяда
Парын югалткан кеше.

Караңгылык кочагында
Юк шул ул, юк,  ул җылы.
Яңгыр коя, күңелемнең
Өзгәләнә мең кылы.

Төн уртасы, яңгыр ява,
Булмый йокыга талып.
Мөгаен, кемдер бүген дә
Елый ялгызы калып!

***

Соңгы җәем булма, җәем,
Чәчәкләрне яратам.
Гашыйкмын мин тал-тирәккә,
Яшеллек дип җан атам.

Соңгы көнем булма, син көн,
Якты өмет бар миндә.
Көч бар әле, авырлыклар
Йөрсен әйдә иңемдә.

Соңгы җырым булма, җырым,
Иртә әле, иртәрәк.
Типсен дә, типсен әле ул
Җыр белән тулы йөрәк.

Булсын килер шатлыкларым,
Булсын кайгыларым да.
Бу бит байлык, яшәү дигән
Иң зур бәхет барында!

***

Тамагым– тук, өстем бөтен,
Бар кайгым, бар шатлыгым.
Җитәчәк бар гомеремә
Күңелдәге аклыгым.
Туганнар бар, бар дусларым,
Бар мәхәббәт кояшым.
Көч бар, аумыйм, җилгә каршы
Барам җәеп колачым.
Хыялларсыз булганым юк,
Җыр-моңнарым җитәрлек.
Матур-матур эшләрем бар
Зур бәхетле итәрлек.
Кара әле, юк нәрсәм юк,
Уйласаң таң калырлык!
Бар да алда, Ходаемнан
Көн дә сорар бер нәрсәм бар,
Ул да булса – сабырлык!

***

Үз сүзле булдым, һаман да
Мин –үзем булып калам.
Үзем булып калыр өчен,
Әле көрәшә алам.

Үзем булып калам әле
Мәхәббәт илендә дә,
Хыялларым күгендә дә,
Чәчәкле җиремдә дә.

Җырлаган җырларымда да
Үз сүзле булып калам.
Шуңа да инде тормышның
Бозлы суларын эчәм мин,
Утларын алып кабам!

# ТАБИГАТЬКӘ РӘХМӘТ

Шушы вакыт җитсә тәрәзәдән
Күзләремне алмыйм көннәр буе.
Матур чак шул: җирдә гөрләвекләр,
Агач башларында – кошлар туе.

Өй буенда үсмер ак каеннар
Бии әнә искән җил көенә.
Ботакларда бөре бүрткән чак бу,
Шуны күреп минем җан сөенә.

Яшел яфрак булыр, бөреләрне
Кояш нуры үбә назы белән.
Табигатькә рәхмәт, күңелемә
Көзе белән сагыш сарган иде,
Юатты да инде язы белән!

***

Таралдылар кошлар төрле якка,
Күкәй салдылар да ояга.
Килешмәгәч нигә аерылмаска,
Ике килеп булмый дөньяга!

Һич кызганып тормый шул кошларны
Атар гына идем яраса.
Тукта, тукта, минем әйтер сүзем
Кош турында түгел, ләбаса.

Тормыш инде бетте чуарланып,
Ятим сабый арта көн саен.
Кичерсеннәр кошлар, юк, аларда
Кешеләрнең, әйе, кешеләрнең
Явызлыгы юктыр, мөгаен!

***

Таш күтәрмәдә эт ята,
Ул хуҗасын көтәме.
Әллә юкмы үз хуҗасы,
Җанын ачлык өтәме?

Ишек ачып керәләр дә,
Чыгалар да, эт өрми.
Әйтерсең лә, ис тә сизми,
Дөм сукырайган, күрми.

Әйе, ач ул, хәлсезләнгән,
Димәк, хезмәт итмәгән.
Урам эте булган бары,
Шуннан ары китмәгән.

Тормыштан бер ямьсезлек бу,
Дөньяны алган урап.
Эт - эт инде, кешеләрнең
Бар ишеккә килгәннәре
Ипи телеме сорап!

* * *

Түзәрмен, тулса гел тулсын
Күңелем сагыш белән.
Ходаем, сакла җанымны,
Тулмасын каргыш белән.

Гомерем буена мине
Иманлы ит, и Аллам.
Каргыштан куркам, җәзасын
Күтәреп йөртә алмам!

## ТАТАР КЕМ УЛ?

Татар күпне күргән милләт,
Авырлыктан куркып калмый.
Зур тормышка ямьнәр өстәп
Эшли белә армый-талмый.

Татар– моңлы-җырлы милләт,
Саф күңеле Иделдәй киң.
Матурлыгы, тиңе булмас
Иген үскән кырларга тиң.

Горурлыгы таудай биек,
Мәхәббәте бәя белми.
Татар юкка яшен түкми,
Сәбәпсездән генә көлми.

Алтын - көмешләрдән кыйммәт
Теленә, юк, тел тидертмәс.
Җилдәй генә кагылсыннар-
Сөйгәнен дә гафу итмәс!

Сер сандыгы бар татарның,
Бар уй-хыял, күрәчәге!
Бишектәге сабый, ә ул -
Милләтемнең киләчәге!

***

Хыянәт – ул саф күңелдән
Җуелмый торган кара.
Йөрәгеңдә гел әрнегән,
Төзәлә белмәс яра.
Хыянәтне гафу итә
Алган көч бар сөюдә.
Тик матурлык бармы соң ул
Башны түбән июдә?!

## ТАНЫШЫМА

/Т. Нуриманга/

Изгелегең, синең саф күңелең
Кояш булып балкый күгемдә.
Әйтеләсе чиксез рәхмәтләрем
Шигырь булып туды күңелемдә.

Кеше хәлен аңлый белгән өчен
Уң булачак һәрчак юлларың.
Гел иминлек булыр гаиләңдә,
Бәхет кошы тотар кулларың.

Их, синдәйләр күбрәк булсын иде,
Синең җанда яши нур-иман.
Азан белән кушкан исемеңә
Азаккача тугры калырсың син,
Мин ышанам сиңа, Нуриман!

## ХЫЯЛЫМДА КИЛӘЧӘГЕҢ

/Төхбәтуллин Әмир Нуриман улына/

И сабыем, күзләрең йом,
Татлы йокың йокла.
Әткәң - әнкәң синең янда,
Кайгыларың юк ла.

Бишегеңне тирбәтсеннәр
Фәрештәләр генә.
Йокы теләп тәрәзәдән
Ай нур сибә, әнә.

Күргән төшең матур булсын,
Уянма син елап.
Шигырь язам, хыялдагы
Зур кояшлы яңа көнне
Бәхетеңә юрап.

## ТЕЛӘГЕМ

Рухыма көч бир, Ходаем,
Миңа сынмаска кирәк.
Бөгелмәсен күңелемдәге
Сандугач кунар тирәк.

Акылыма камиллек бир,
Җаныма бир сабырлык.
Миңа карап, башкаларга
Булсын үрнәк алырлык.

Исәнлек бир, килә яшәү
Ялкынында янасым.
И Ходаем, кодрәтең бир,
Бар әле, бар язасым.
Дәвалыйсым бар җыр белән
Кайгылының ярасын.
И Ходаем!

## ТУГРЫ КАЛАМ

Мине бәла - казалардан
Фәрештәләрем саклый.
Кыенлыклар кыерсытса,
Таянырдай терәк тапмыйм,
Фәрештәләрем яклый.
Була бит ул: "Беркемгә дә
Ышанмам!" – дигән чаклар.
Иманыма тугры калам,
Иңемдәге фәрештәләр
Ышанычымны аклар!

***

Тәгәрәде күз яшьләрем,
Бит алмамны чылатып.
Әйе, әйе, миңа сөю
Шулай килде, елатып.

Кызлар, гашыйк булгач нигә
Шулай елыйбыз икән?
Еллар үткәч искә, алсаң,
И кызык була икән!

Мин әле дә өзелеп сөям,
Ялкыннарым яшьлектән.
Тик үзгәрдем, сабырландым,
Елаганым юк күптән.

Яратам, дип, юк, еламыйм,
Көмешләнде чәчләрем.
Яратам, дип җырлар язам,
Димәк, моңга әверелгән,
Ләйсәндәй саф яшьләрем!

***

Түзәм, дисәң түзеп була да бит,
Барсына да нигә түзәргә!
Сулы савыт өчен чәчәкне дә
Вакытында кирәк өзәргә!

Соң, нәрсәнең генә юк ул чиге,
Түзүнең дә булыр азагы!
Юк, җил генә түгел, давыл булып
Кузгалырга кирәк, әрнеткәнче,
Үкенүнең авыр газабы!

## ТУГАН КӨНЕМДӘ

Их, әнкәем исән булса,
Кайгы төсен белмәс идем.
Җил-яңгыры, хәнҗәр булып,
Бәгыремне телмәс иде.

Сагынып минем сабый чакны
Әнкәй мине сөяр иде.
«Зур үскәнем, күгәрченем,
Акыллым син!» – дияр иде.

Әйтмәс иде: «Илле бишкә
Җиттең инде!» – дигән сүзен.
Карашлары назлар иде,
Алмас иде миннән күзен.
Их, әнкәем!...

## ТОТКЫНДА ӘЛЕ ЯШЬЛӘР КҮП

Күбәләк килеп эләкте
Үрмәкүч үргән ояга.
Үрмәкүчне әйтәм, шундый
Явызлыкны кылыр өчен
Яралган икән дөньяга.
Чәчәктән чәчәккә кунып
Уйнасын иде күбәләк,
Гел матурлык белән тулып.
Дөнья әнә кояш кебек
Булыр иде түм -түгәрәк.
Хәер, ни әйтсәң дә монда,
Күбәләк үзе гаепле.
Бу хәлләргә калмас иде,
Җанын утка салмас иде,
Яши белсә әгәр ипле!

## ТӨННӘРЕМ ҖЫРЛЫ

Көннәремне көтеп алам,
Көннәр кояшлы, җылы.
Төннәрем дә көткән кунак,
Минем төннәрем җырлы.

Төн пәрдәсе тартылуга
Аллага шөкер, димен.
Бүген дә, дим, исән-саумын,
Көнкәем үтте имин!

Урынга яткач теләкләр
Телим, йокыга талмыйм.
Һәр төн саен җыр иленә
Сәяхәт кылмый калмыйм

Йокысыз үтсә үтә төн,
Таң каршылыйм җыр белән.
Яшәвемнең мәгънәсе бу,
Бәясен үзем беләм!

***

Үзе иркен, нурга тулы күк булса да,
Бар кошларның очып уйнар дөньялары.
Юк, озакка калалмыйлар алар күктә,
Җирдә җыяр ризыклары, оялары.

Хыял канатларым белән югары мин,
Ай-Кояшка якынрак була алам.
Кош түгелмен, кеше була беләм, шуңа
Чын тормышта яшәр өчен җирдә калам!

***

(Тукайга иртәгә – 115 яшь)

Хәтерли Кырлай яклары
Тукайның елаган чагын.
Онытмый Башкортстаным
Тукайның җырлаган чагын.

Елаткан аны ятимлек,
Җырлаткан аны сөюе.
Сүрелми, сүнми бүген дә
Тукайның яну -көюе.

Халкым, дип әйтсәм –Тукайдан,
Тел, дисәм дә, нәкъ Тукайча.
Әйтерсең, апрель җилләре
Алдыма куеп, Тукайның
Җыр тулы дәфтәрен ача!

***

Үлем түшәгендә ята кеше,
Күпне күргән гомер юлында.
Кайгы килгәч, бәхет кошкае да,
Булды микән аның кулында?

Рәхмәтлеме якты бу дөньяга,
Югалтканмы күбрәк, тапканмы,
Гомеркәе искән җил булганмы,
Комлы сулар булып акканмы?

Үлем түшәгендә ята кеше,
Әйтә алмый сүзен аңлатып.
Тик шунысы мәгълүм, яшәгән ул,
Яшәү өчен җанын канатып!

## ҮЛЕМ КИЛМӘСЕН

Кайгы -хәсрәтләрем бар, дип,
Башың түбән имә син.
Кайгыларны җиңәр көч бар,
Үлем генә килмәсен!

Көрәш, давыллары белән,
Көчем җитмәс, димә син.
Кояшлы, Айлы дөньяңа
Үлем генә килмәсен!

Яшәү дигән матурлыкка
Күзләр генә тимәсен.
Бер туабыз, бер яшибез,
Үлем ашыгып килмәсен!

## ҮЗГӘРДЕМ

Чирем әлле ничә төрле,
Шулай да, кәеф ару.
Берсен ашыйм, берсен эчәм,
Бер шкаф миндә дару.

Авырганда, үләрмен, дип,
И курка идем элек.
Хәзер үлмәс кебек яшим,
Әйтерсең, мин– мәңгелек!

Эшлим, күз дә йоммый әйтәм,
Мин әле кирәк кеше!
Кеше үзгәрә икән ул,
Башкаларга шатлык кына
Китереп торса эше.
Язам!

## УКЫСЫННАР

Якты дөнья торып калды,
Мәңгелеккә йомдың күзең.
Тыныч йокың йокла, эткәй,
Баш астыңа китап куйдык,
Шулай кушкан идең үзең.

Укырга бик яраттың син,
Китап җыйдың киштә -киштә.
Эштән кайткач, китаплардан
Ашап утырганда да бит
Аерылмый идең һич тә.

Ачуланма миңа, зинһар,
Берүк җаның рәнҗемәсен.
Авыл китапханәсенә
Синнән калган китапларның,
Бүләк итәм берничәсен.

Син укыган китапларны
Укысын, дим, яңа буын.
Күп укыдың, күпне белдең,
Шуңададыр, димен, син бит
Матур үттең гомер юлын.

Үземдә дә китапларың
Кала, эткәй, төсең булып.
Кичерә күр, укысыннар,
Китапларны бүләк итәм,
Күзләремә яшьләр тулып.

***

(Ф. Зиләгә)

Юк, ялгыш та әйтмә берүк:
«Күзләремә життем!» –дип. –
«Шау чәчәкле язларымнан,
Инде ерак киттем!» –дип.

Яз ямьнәре, яз җылысы
Үзең белән бүген дә.
Балкып торган Кояш күрәм,
Синең күңел күгеңдә.

Телең татлы, йөзең якты,
Тоташ назга тулгансың.
Сере шунда: син бит, дускай,
Яз аенда тугансың!

Яшә!

***

Ут булып дөрләдем, сүндем мин су сипкәч,
Диңгезгә, океанга әйләнеп карадым.
Дулкыннар кочагын үз итә алмагач
Тын ярын эзләде зур тормыш корабым.

Гөл булып карадым, кар яуды, өшедем,
Кош булдым, җил –давыл канатым каерды.
Булдым мин күктәге кояш, ай һәм йолдыз,
Кирәкми бу хыял, җиремнән аерды.

Җиремнән китмәскә әйләндем чишмәгә,
Комташлар өеме туктатты җырымны.
Уяндым хыялдан, мин кеше, мин кеше,
Мин матур, мин сабыр, мин көчле, тормышка
Бирәм үз җырымны, бирәм үз җылымны.

## ҮРНӘК АЛЫЙК

Кеше гомере кыска, диеп,
Әйтүе оят безгә.
Түтәлдә үскән чәчәкләр
Мөлдерәп карый күзгә.

Гүя алар әйтә кебек:
Зар  елавы– зур хурлык.
Бер генә җәй яшәсәк тә,
Өләшәбез матурлык!

***

Урам эте, шатлыгым бар,
Миннән хәер кабул ит.
Туен әле, бирәм сиңа
Тукмачлы аш, майлы ит.

Әбиләргә хәер бирмим,
Алар миннән күпкә бай.
Сынадым инде, аларга
Только давай да, давай!

«Күпме бирер микән!» -диеп,
Кулыңа карап тора.
Күп бирмәгәнеңне күреп,
Карашын читкә бора.

Урам эте, сиңа хәер
Бирү дөрес, минемчә.
Син сөенсәң,шатлыкларым
Булыр күк әллә ничә!

## ҮЛМӘС ӨМЕТ

Үлем түшәгендә ята, ләкин
Дару ашый, тереләсе килә.
Дөнья тулы кояш яктысына,
Гөлләр булып үреләсе килә.

Иртәгәме, әллә бүген үкме,
Мәңгелеккә йомар ул күзләрен.
Теле барда якын кешесенә
Әйтә алды микән соң сүзләрен!

Юк, чыкмаган әле аның җаны,
Яши бит ул һаман тоеп җылы.
Үлмәс өмет белән уйлыйдыр ул,
Бардыр әле, диеп, җырлар җыры!

***

Хәлләремне аңлый белмәгәннәр
Юк түгелләр, алар янымда.
Үзем генә беләм, нинди генә
Утлар янмый минем җанымда!

Хәлләремне күрә белмәгәннәр
Очрап тора минем тирәмдә.
Гомер итәм шулай, һәр көнемдә
Бәгыремне меңгә телә м дә.

Хәлләремә керә белмәгәннәр
Юлдаш булып янәш баралар.
Тешне кыстым, соң, нишләмәк кирәк,
Таба алмыйм башка чаралар!

***

Ходай миңа таудай итеп
Өеп биргән авырлыкны.
Хәлләремнән таймас өчен,
Сорап алам сабырлыкны.

Күп сорамыйм, Аллакаем,
Сабырлыклар бирсә җиткән.
Ходаема рәхмәтем зур,
Мең газаплы бу тормышны
Сөеп яшәү насыйп иткән!

***

Хисләремнең мөлдерәмә
Түгелеп торган мәле.
Кар-энҗеләр тезеп кенә
Бер шигырь язам әле.
Ялкынымда эреп бетәр
Бу кышның ак карлары.
Үсәр җирдә чәчәкләрнең
Иң –иң –иң матурлары.
Кар бөртеген җиләк итеп
Алырмын кулларыма.
Кагылыр тик назлы җилләр
Күңелем кылларына.
Арыш, бодай башаклары
Шаулаган чакта кырда,
Тургай булып талпынырмын,
Юк, утырмам фатирда.
Менә әле килер җәйне
Күрәм кар-буран аша.
Хыялларга ышанам мин,
Хыял тормышка аша.
Хыял тормышка аша!

***

Хәмер исе килә үсмер кыздан,
Хәмер исе килә энилərдән,
Хәмер исе килә әбиләрдән!

Хәмер исе килә хатын-кыздан,
Тормышта ямь тәмам бетеп бара.
Соң, бу фаҗигадән нәрсә кала,
Гүзәллектән башка яшәп кара!

Бүгенге көн белән килешмимен,
Килер көннәр өчен хафаланам.
Бишектәге кыз туганым өчен
Тирән уйларымда туңам, янам!

***

Тәрәзәмдә боз эреде,
Җылытты бугай көнне.
Күңелдәге боз туң көе,
Төшме бу, әллә өнме!

Берәү минем күңел күлен
Тоташ бозга катырды.
Ни хәл кәтә, эрерме боз,
Күлгә аккош кайтырмы!

Явызлык белән яшәмәм,
Бозларын чәчсен ул гел.
Гафу итәрмен, мин үзем
Боздан яралган түгел!
 Юк, юк, боз булып калмый ул
 Гөлләргә гашыйк күңел!

**ХӘЕРЛЕ ЮЛ!**

Хәерле юл, кошлар,
Хушыгыз.
Еракларга китә
Юлыгыз.
Юлларыгыз булсын
Киртәсез.
Матур язны эзләп
Китәсез.
Мин көтәрмен сезне
Сагынып.
Күңелем канатларын
Кагынып.
Хәерле юл, кошлар,
Китәсез.
Кайтып шатлык бүләк
Итәрсез.
Мәхрүм булмам әле
Назлардан.
Мин җыр көтәм килер
Язлардан.

***

Чәчемне тарасын әле җил,
Исә бит авылым ягыннан.
Әйтерсең, матурлык агыла
Гомернең чәчәкле чагыннан.
Җаныма илаһи моң иңә,
Сабырлык, сынмыйча түз, яме.
Өзелеп - өзелеп сагыну да,
Күрәсең, яшәүнең бер яме!

***

Хыял дәрьясында йөзәм,
Күңелем ак җилкән.
Бер кайгы да белми яшәү
И рәхәт икән!

Һич чынбарлык кебек түгел
Бу дөнья үзгә.
Бары тик сихри ямь генә
Күренә күзгә.

Монда язмыш богауларын
Ташлыйсың өзеп.
Гомер итәсең тик бәхет
Күлендә йөзеп.

Сөйгәнеңнән ишетәсең
Гел назлы сүзләр.
Күкрәк тулы көч -дәрт синдә,
Яулана үрләр!

Юк, бу тормышта шулай бит,
Хыялым түгел.
Бу бер мизгел, нигә икән
Шулай булмый гел!

**ШАТЛАНЫЙМЧЫ**

Тәрәзәмне боз каплады,
Кояш, бозны эрет тизрәк.
Шау чәчәкле булыр өчен,
Гөлләремә якты кирәк.

Нурларыңны жәлләми түк,
Синнән җылы көтә гөлләр.
Кояш, назла гөлләремне,
Кире кайткан кебек булсын
Әнкәм бар чактагы көннәр.
Шатланыймчы!

## ХЫЯЛ!

Май яңгыры, җир йөзенә
Сибеләсең наз булып.
Чәчәкләрне кочасың да
Елмаясың яз булып.

Үсмер кызның күз яшендә
Күрәм синең сафлыкны.
Көмеш тамчыларың итеп
Җыйгансың бар шатлыкны.

Тәрәзәмә карлы яңгыр
Бәреп яуган бу көндә.
Юк, өшетми, май яңгыры,
Син яшисең күңелдә.
Караңгыдан тартып алган
Якты өмет бар әл дә!

***

Чирне җиңеп булмый аны
Уфылдап та, ыһылдап.
Барыбер бирешмәм, дисең,
Җиңеп куясың чынлап.

Кайгы килгән чакларда да
Яраланып әрнисең.
Әрнесәң әрнисең, ләкин
Башны ташка бәрмисең.

Кайгы белән чир гел көтә
Синең егылуыңны.
Ә тормыш ул таләп итә
Гел көчле булуыңны!

## ХУШЛАШУ

(С.Әкълимә апаны озату)

Исән кайттың сугыш яланыннан,
Хезмәт ямең бирдең иленә.
Гашыйк итте сине туган телең,
Гашыйк идең туган җиреңә.

Хатын-кызда булган матурлыкның
Барсына да ия булдың да,
Яшәдең син, аллы-назлы булып,
Гөлләр үсте тормыш юлыңда.

«Укытучым!» –диеп эндәштеләр,
Хөрмәт белән карап күзеңә.
Сөю турындагы шигырьләрең
Озата килде гомер көзеңә.

Түтәлләрдә гөлләр боектылар,
Назлы җилләр сөйми аларны.
Көзге җилләр түгел, кайгы җиле
Өшетә шул бүген җаннарны.

Озатабыз сине соңгы юлга,
Хушлашуы ай-һай, бик авыр.
Инде тыныч йокла, каләмдәшем,
Җырларыңда озак яшәрсең син,
Исемеңә тимәс җил-яңгыр!

## ЧЫН ӘЙТӘДЕР

Чәчеңне ник буятмыйсың,
Яшәреп китәр идең.
Егет затын әле тагын
Хыялый итәр идең.

Синең өчен ялкыннарда
Кем генә янмас иде.
Мәхәббәтен шигырь итеп
Кем генә язмас иде!"

Шулай диләр танышларым,
Урамга чыккан саен.
Кагылып чал чәчләремә,
Рәфис миңа: "Яратам!" – ди,
Чын әйтәдер мөгаен!

***

Читлектәге кошның хәлен беләм,
Гомер буе үзем читлектә.
Язмыш читлегенең ишекләрен
Табып ачып булмый ничек тә.

Читлектәге кош мин, канатларым
Җилпесәм дә очар күгем юк.
Сабый чактан кулсыз, аяксыз мин,
Яралады җанны кайгы-ук.

Болай гына әйтеп үтүем лә,
Юк, зарлану миңа хас түгел.
Исән әле миндә читлекләрне
Ватып чыга алган кош-күңел!

## ЧӘЧӘК ҮЛЕМЕ

Җир өстендә беренче кар,
Күңелдә шатлык.
Тукта, кинәт кап- карага
Әйләнде аклык.

Түтәлдәге чәчәкләрне
Туңдырган суык.
Моңсуланып калган бакча,
Кичәге ямь юк.

Беренче кар, син эрерсең,
Тик менә гөлләр!...
Булмас инде гөлләр өчен
Шатлыклы көннәр!

Кайвакытта күз яшенә
Булмый киртәләр.
Җансыз калган чәчәкләрем
Табуттагы яшь солдатны
Хәтерләтәләр!

***

Эт гомере буе өрә,
Өреп үтә көне – төне.
Үлем җиткәч, чыйный гына–
Өреп беткән була өне.
Эттәй өргән кешеләр бар,
Яши белми "ау – һау"ламый.
Килер ул көн, якынына
Соңгы сүзен әйтә алмый
Китәчәген ник уйламый?

## ШАТЛЫГЫМА ЮРЫЙМ

Сарытүшләр килеп куналар да
Ак каенның толым чәченә,
Оеп кына яткан кар өстенә
Энҗе бөртекләре чәчелә.
Талгын гына җилләр җилпенсә дә
Челтер-челтер тәңкә коела.
Тәңкә карлар иңнәремнән кочкан
Челтәр шәлем булып тоела.
Җилфер-җилфер ефәк тасма кебек
Кар сибелә, күрче, күр әле.
Күңелемдә яши бер җыр булып,
Матурлыкның сихри бу мәле.
Күргән саен карлы тирәкләрне
Иркәләнә минем күзләрем .
Җаным тулы якты өмет белән
Шатлыгыма юрыйм үзләрен!

## ШАТЛАНАМ

Кар өстендә калган чаңгы эзе,
Тукталган ул чыршы янында.
Шатлыгым зур, шөкер, бу бәндәнең
Иманы бар икән җанында.

Юк, кисмәгән, исән нәни чыршы,
Иңнәрендә ап-ак кар ята.
Нәфрәтле мин, яшел гүзәллекне
Харап иткәннәргә карата.

Кар өстендә калган чаңгы эзен
Ак бураннар күмеп китәчәк.
Нәни чыршы янә Яңа елны
Урманында бәйрәм итәчәк!

***

Шәһәрдә дә язлар матур ләбаса,
Сандугачлы икән киче, таңнары.
Тик барыбер, тыңлаганда кошларны,
Күз алдымда авылымның таллары.

Шәһәрдә дә яшел хәтфә үлән бар,
Ун бәбкәле ала казны юксынам.
Авылда ул, ерак калган елларда,
Җанны өтә сагышларым ут сыман.

Шәһәрдәге фонтаннарны күргәндә,
Күңелкәем өзгәләнми нишләсен!
Җырларыма моңнар итеп алам мин
Авылымның чылтырап аккан чишмәсен.
Әй, язмыш!...

## ШАГЫЙРӘ МИН

Дөньяга туганмын,
Яшимен,үләрмен.
Сөюдән туганмын,
Гөл булып яшимен,
Ут булып сүнәрмен.

Юк,килми сүнәсем,
Балкыплар яныймчы.
Ялкынлы сүз белән
Җандагы бозларны
Эретеп калыймчы!
Сүнәрмен!

## ЫШАНДЫМ

( «Җан күбәләк булып кайта»)

Әткәй, әнкәй, дөньялыкта
Сез гел бергә идегез.
Рәхмәт, безнең сабыйлыкны,
Юк, ятим итмәдегез.

Урыныгыз янәш түгел,
Куеп булмады бергә.
Җаннарыгыз бергә микән,
Шуны ничек белергә!

Төшем түгел, баш очымда
Уйный ике күбәләк.
Чынлап икән, инде менә
Күңел -дөньям түгәрәк!

***

Эчкән суым тәмле шәһәрдә дә
Ник кайтам соң һаман авылга!
Әйләнәм дә кайтам, юлларымда
Очрасам да каршы давылга.

Җырларымда шәһәр гүзәллеге,
Иң матур җыр –авылым хакында!
Гомер буе шулай, авылым, дип
Яшәрмендер сагыш –ялкында,

Шәһәрдә дә дуслар, туганнар бар,
Күршеләрем– бар да үз кешем.
Кайтмый булмый, менә бүген дә бит,
Бер уч туфрак алып иснәр өчен,
Авылыма кайтып килешем!

## ЫШАНАМ

Күзләргә күз карашканда,
Кирәк тә түгел сүзләр.
“Яратам!” –дисең, ышанам,
Барны сөйли ул күзләр.

“Син гомерлек, ярым!” –дисең,
Амин, әйткәнең булсын!
Озын булсын гомеребез,
Безнең сөюдән җир йөзе
Чәчәкләр белән тулсын!

## ШУНЫ БЕЛДЕМ

Йөрәгемдә бик күбәйде
Югалту яралары.
Даруларны ешрак кабам,
Юк башка чаралары.

Дәшеп кенә алыр идем,
Җир йөзендә булсалар.
Мәңгелеккә киттеләр шул,
Җир куенында алар.

Шуны белдем, азак әрнеп
Гомер итәсең икән.
Үлем шул, димәк, дөньядан
Мәрхүм булган якыннарны
Эзләп китәсең икән!

## ЭТКӘ

Эт, улама, күңелемә
Салма шом.
Өрмә дә син бер дә юкка,
Авызың йом.
Тешләмә дә бар ул миндә
Яралар.
Җанымда да, тәнемдә дә
Бар алар.
Мөлкәтемә җил –яңгырлар
Тидермә.
Явыз бәндәләрне якын
Китермә.
Тугры дустымдай җаныма
Бир җылы.
Синнән иминлекләр көтәм,
Эт елы!

***

Энҗе-энҗе булып сибелә кар,
Тәрәзәдән алмыйм күземне.
Ак чәчәкле, ап-ак күбәләкле
Болынлыкта тоям үземне.
Ак кар булып ява яңа шигырь,
Ак кар булып ява яңа җыр.
Кар яуганда килә күз алдыма,
Башак шавы белән тулы кыр.
Күңелемә якты өмет булып
Иңә бара яуган ак карлар.
Урам тулып очкан кар-энҗеләр
Сез дусларым белән уртаклашыр
Килер шатлыкларым бит алар.

***

Әй, кешеләр, беләсез ич,
Без –табигать баласы.
Баласыннан кадер-хөрмәт
Күрәме соң анасы?

Юк, әнә күр, су буйлары
Чуп-чар белән туп-тулы.
Югыйсә бит, безнең якта
Чишмәләр тәмле сулы.

Табигать безгә ямь бирә,
Тукландыра, иркәли.
Без шулай ук мәрхәмәтсез,
Игелексез микәнни!

Чәчәк үсәр, җиләк пешәр
Ялан-кырлар чүп-чарлы.
Шуңа да бит минем бүген
Язган шигырем зарлы.

Ата-ана каргышына
Дучар булмыйк, сак булыйк.
Без табигать баласы бит,
Йомшак булыйк назлы җилдәй,
Ак каендай ак булыйк!

## ЯЗ КИЛСЕН

Сары яфрак, әйт, син кемнең сагышы,
Кем җанынннан чайпалыплар түгелдең?
Сине күргәч өзгәләнәм, сызланам,
Тыныч кына булганы юк күңелнең.

Сары яфрак, салдым сине учыма,
Җылымны ал, яшәр, җиргә яз килсен.
Сагынулар белән газап кичергән
Күңелләргә язлар белән наз килсен.

## ЯЗ ТАВЫШЫ

Челтер-челтер иткән тавыш килә,
Нәрсә соң бу, ишетәмме чынлап?
Яз тавышы икән, урамнарда
Гөрләвекләр агып ята чыңлап.

Яз тавышы булып җанга сеңгән
Тамчыларның тып-тып тамулары.
Ишетелеп тора бүген, хәтта
Бөреләрнең сулыш алулары.

Яз тавышы, диме, ни диярсең,
Кошкайларның канат җилпүләрен?
Бәйрәм итә күңел шул кошларның
Туган җиргә кайтып җитүләрен.

Яз тавышы килә басулардан,
Яз тавышы көннәр балкышында.
Күкрәгеңне тыңлап кара әле,
Яз тавышы йөрәк кагышында!

## ЯҢА ЕЛ ЯКЫНЛАША

Яшәлгән елым, хуш инде,
Яңа ел якынлаша.
Юк, онытмам сине, искә
Алырмын еллар аша.

Шатлыкларым өчен рәхмәт,
Кайгылар да кичердем.
Көлдем дә мин, еладым да,
Күрәчәгемне күрдем.

Алда да шул булыр инде:
Өшермен дә, янармын.
Бүгенгедәй, яшим бит, дип,
Куанып җыр язармын.

Амин, шулай булсын берүк,
Өметләрем аклансын.
Һәркемгә ямь өләшермен,
Ал чәчәкле булсын җәйләр,
Кышлар ак булып калсын!

## ЯВЫЗЛЫКНЫ ҖИҢӘР КӨЧ БАР

Явыз бәндә – кара елан,
Чага, чагып үтермәкче.
Вакытыннан күпкә алда
Кабереңне ул күрмәкче.
Көрәшергә туры килә,
Еланның мин башын өзәм.
Явызга үз явызлыгы
Кире кайта, шуны белеп,
Тешләремне кысып түзәм.

***

Явызлык күп, үлчәп кенә
Бетерермен, димә.
Юк, кара көч алдында син
Берүк башың имә.

Яраланып әрнесәң дә
Сихәтләнерсең бер.
Актан ак бул, күңелеңдә
Саклап йөртмә син кер.

Тормышка ямь генә бирә
Торган булсын эшең.
Булсаң бул син минем кебек,
Явызлыкның чылбырларын
Чәйнәп өзә тешем!

## ЮЛДАМЫН

Сикәлтәләр ай- һай бик күп,
Азаккача чыдармынмы,
Түзә - түзә бара торгач,
Шома юлга чыгармынмы?

Бар микән ул бу тормышта
Җиңел генә менәр үрләр?
Бар, ди, әнә, җип-җиңел, ди,
Нәрсә уйлыйм, әй, мин юләр!

Мине менә шушы юлым
Бәхетемә алып бара.
Бәхет кирәк булса, син дә
Авырлыкны җиңеп кара!

## ЮК ЛА БАШКА ЧАРАСЫ

Чәчәкләргә тиң чагымны эзләдем,
Юк, тапмадым, калган бары эзләрем.
Җанга эзләр сагыш булып уелган,
Әй,гүзәл чак, бер күренсәң ни булган!

Гомер көзем колагыма пышылдап:
"Ай-һай син, –ди,– сагынасың бит чынлап.
Яшә генә, җиргә җәйләр киләчәк,
Яшьлегеңне хәтерләтер һәр чәчәк!"

Инде хәзер саный-саный көннәрне,
Җәйне көтәм,күрер өчен гөлләрне.

***

Язны көтә күңел, әллә шуңа,
Күкләр күкри көзләр җитсә дә.
Аерыласы килми яздан, еллар
Чәчләремне көмеш итсә дә.

Бик яшисем килә, әле тагын
Серем сөйләп үскән гөлләргә.
И, янасы килә ялкынланып,
Сүнми генә искән җилләргә.

Җыр язасым килә гашыйк булып,
Бер яшьнәсем килә, күкрәсем.
Гомер көзем, кичер, минем сине
Яшел итеп килә күрәсем!

## ЯЗМЫШЫМ

Язмышым, сине күтәреп
Барам гомер юлымнан.
Авырсың, чак-чак төшерми
Калдырамын кулымнан.

Әй, суык синең җилләрең,
Үзәккә үтеп исә.
Кызганмый ул, күңелемнең
Гөл сабакларын кисә.

Кайгылар җанны тураклап
Куыра үз утында.
Җиңәм дә бит, бик авыр шул
Елаткан минутында.

Язмышым, син җимешнең дә
Каптырдың җитмәгәнен.
Бирдең миңа мәхәббәтнең
Бәхетле итмәгәнен.

Сүзләрем үпкәләү булып
Ишетелмәсен ялгыш.
Ни күрсәм дә язганы шул,
Күкрәгемә кысам сине,
Минеке бит, син язмыш!

## ЯЗМЫШТАШКА

Ходай үзе яраткан бит
Агын да, карасын да.
Бәхетсезе бар бәхетле
Язмышлар арасында.

Кимсенеп имә башыңны,
Килешми безгә моң-зар.
Без генә түгел бит әле,
Чәчәкләр арасында да
Зәгыйфь чәчәк күргән бар!

## ЯКТЫ БӘЙРӘМ

Укытучы! Синең хезмәт юлың
Якты булган өчен мактаулы.
Биек үрләр яулап алыр өчен
Үткән юлың ай-һай катлаулы.

Күзләреңә бага зур киләчәк,
Кыңгыраулар чыңы-синең моң.
Җимешләрең татлы, синең өчен
Шуннан башка бәхет бармы соң?!

Тормыш өчен ныклы терәк булып
Өлгерәләр кыз һәм улларың.
Хыялларың аша чынбарлыкка,
Алга килә изге уйларың.

Укытучы! Кабул итеп алчы
Күңелләрнең чәчәк бәйләмен.
Бүген сиңа дөнья сөеп карый,
Синең бүген якты бәйрәмең!

## ЯЗАМ ӘЛЕ

Язам әле, һаман язам,
Нигә әле язмаска?!
Нечкә билле таллар булып,
Нигә яфрак ярмаска?!
Язам әле, кошлар булып,
Нигә канат какмаска?!
Челтер-челтер чишмә кебек
Ник моң булып акмаска?!
Язам, янар йөрәк барда
Ник "Яратам!" – димәскә?!
Яза-яза күкрәгемә
Көч туплыйм мин, авырлыктан
Башны түбән имәскә!

***

–Яфрак, син бит яшел идең,
Сары төскә кергәнсең,
Әйтерсең лә гомерең буе
Күп кайгылар күргәнсең.

–Юк-юк, кайгы күрмәдем мин,
Гомерем рәхәттә үтте.
Җылы яңгыр юды мине,
Кояш нурлары үпте.

Җәйге җилләр йомшак иде,
Инде менә көз җитте!
Тынып калды сары яфрак,
Рәхмәт аңа, шигыремне,
Кайгы –сагышсыз итте!

***

Ялкын булсам – су сибәрләр,
Чәчәк булсам – өзәрләр.
Аккош булсам, күкрәгемә
Явызлар ук төзәрләр.

Тау булсам да ишелермен,
Тау җимерер көчләр бар.
Алсу таңнар булам, димим,
Сөю тулы кичләр бар.

Чишмә булып ургылсам да
Мәңгелек булмас көчем.
Болыт каплар, юк, кызыкмыйм,
Ай, Кояш булыр өчен.

Таллар булсам – бөгелермен,
Каен булсам – сынармын.
Кеше булып кына калам,
Кеше булуым белән генә
Барсына да чыдармын!

***

Яратмыйм мин кешеләрнең
Сөйләшмәгәнен,
Бар дөньясын ачып салып
Серләшмәгәнен.
Ул бит җылы бирә алмый,
Күңел түренә.
Бары җанны өшеттереп,
Янымнан шуышкан елан
Булып күренә!

## ЯКТЫ ӨМЕТ

Авылымда бөтенесе
Алтмыш ике йорт - нигез.
Монда яшәүчеләр саны –
Йөз дә егерме сигез.

Күпләре өлкән яшьтәләр,
Бертөрле язмышлылар.
Күпне күргәннәр шул инде,
Ялгызлар, сагышлылар.

Тынып калган бала-чага
Белән тулы урамнар.
Бүген җансыз урамнарда
Уйный тик ак бураннар.

Эшкә йөргәннәр күп түгел:
Яшьләр бик аз авылда.
Шушы газиз җиркәемне
Нәрсәләр көтә алда!

Чү! Бәби елаган тавыш
Ишетелә бер йорттан.
Өмет балкый, үз-үземә
Әйтәм: “Авыл яшәячәк,
Куркасың бер дә юктан!”

## ЯЗНЫ КӨТҮ

Көннәр язга авышканны
Гөлләр сизде, яңаралар.
Язлар, җәйләр җитсен әле,
Шау чәчәктә булыр алар.

Кыш буена тәрәз аша,
Кар яуганны күзәттеләр.
Ак бураннар тынды, гөлләр
Кәефләрен үзгәрттеләр.

Бүген кояш кичәгедән
Яктырак та, җылырак та.
Гөлләремә карап, җырлап
Җибәрәсем килә хәтта.

Ялкынланып язны көтәм,
Инде шушы яшькә җитеп,
Тоеп яшим үземне дә
Көнгә баккан бер гөл итеп!

## ЯШӘРГӘ БУЛА БИТ

Йокыда үткәрсәм төнемне,
Язышып үткәрсәм көнемне,
Хәлальдән булса аш-суларым,
Җанымны өтмәсә уйларым,
Иминлек булса йорт-җиремдә,
Бик борчып тормаса чирем дә
Сау булса туганнар, күршеләр
Һәм мине дус күргән кешеләр,
Куркыныч хәбәрләр алмасам,
Ялгызлык утында янмасам,
“Аллага шөкер!” – дим, куанып,
Яшәргә була бит, яшим мин,
Бүгенге көн белән юанам.

## ЯҢГЫРЛЫ ТӨНДӘ

Төн елый, күз яше –яңгыр
Шыбырдап ишетелә.
Шушы мәлдә бер авыр уй
Минем җанымны телә.

Ике бала йоклый, хатын
Төн кочагында калды.
Күз яшьләрен тыялмыйча,
Мендәрен кочып алды.

Сөелер -сөяр чагы бит…
Төн караңгы, төн суык.
Хатынның ир хыянәтен
Кичерергә көче юк!

Төн елый, елый яшь хатын,
Сабыйлар йокыдалар.
Йокысыз төннәр барлыгын
Белми шул әле алар.

## МӘЙДАНДА

Яңавылда шундый ямьле бүген,
Яңавылда чәчәк бәйрәме.
Тик шушында гына, бездә генә,
Бу дөньяның сихри бар яме.

Көн кояшлы, җиле талгын исә,
Мәйдан түре гөлгә бизәлгән.
Саубуллашыр чаклар җитә бит, җәй
Соңгы тапкыр шулай бизәнгән.

Килер җәйне күрәм әле дигән
Өмет белән тулы минем җан.
Ал чәчәкле булсын җирем өсте,
Түгелмәсен берүк җиргә кан!

## ЯҢА ЯЗ

Ак каенның нәни яфракларын
Үбә -үбә кояш нурын сибә.
Яңа язны күрү шатлыгыннан
Җырлый-җырлый минем йөрәк тибә.

Явып үтте җылы яңгыры да,
Искән җил дә юаш, талгын гына.
Яз килә дә һаман хисләремне
Төреп ала кайнар ялкынына.

Үсмер каен, сине күргән саен
Күз алдыма килә туган ягым.
Татлы булып тагын искә төште
Күрше малаена гашыйк чагым.

## ЯШӘҮ МАТУР

Әй, син черки, озын борын,
Эч канымны, эч.
Кан эчүдән башка эшне
Син белмисең ич.

Бер тамчы кан юк, җәл түгел,
Әйдә, яшәп кал.
Бер кабатланмас җаныңа,
Мең куаныч ал.

Сиңа яшәү бүләк итәм,
Көч җый, канны эч.
Яшәү матур, үзем яшәп
Туя алмыйм һич!

## ЯШӘРГӘ ИДЕ ӘЛЕ!

Авырлыкка түзмәгәннәр
Күбрәктер ул, мөгаен.
Үз-үзенә кул салганнар
Арта бара ел саен.

Алдымдагы тәмле ашны
Ярдәмчесез кабалмыйм.
Өстәлемдә кәгазь, каләм,
Юк, үрелеп алалмыйм.

Атлап йөргән чакларымны
Төшемдә күрәм бары.
Иңнәремдә язмышымның
Таудай авырлыклары.

Сабый чактан көнем үтте,
Төнем үтте сызланып.
Яшәү өчен көрәштем мин,
Җиңнәремне сызганып.

Яшәдем, гомернең алтын
Көзенә җиткән мәле.
Туясым юк бу яшәүдән,
Йөзъяшәр әби булып та
Яшәргә иде әле!

## ЯШӘП КҮРСӘТӘМ

Күрсәтәм әле бер яшәп,
Бер кылны меңгә ярып.
Юлларымны дәвам итеп,
Калган чакта да арып.

Утларны яксам ягам мин,
Сүнмәсен дип гомергә.
Сөю утларында йөрәк,
Юк –юк, калмас күмергә.

Ул ялкынны җырым итәм,
Янганнан көл калмасын.
Хисләремне тузан итеп,
Җил күтәреп алмасын.

Авырлыкны егып салам,
Җанымны үртәмәсен.
Җәлләмәсен мине беркем,
Күз яшемне күрмәсен.

Тешләремне кысам әле,
Дөньяны шаккатырып.
Яшисем килә тормышның
Матурлыгын арттырып.

***

Яфраксыз калган каен –кыз,
Төренгән ап-ак бәскә.
Тырыша ул җил -егеткә
Ялангач күренмәскә.

Егет кызга: «Яратам!» – ди, –
Чишен әле, шәрә кал.
Күзләремне иркәлә бер,
Син бит нечкә билле тал!

Кыз да каен кызы кебек
Ояла белсен иде.
Тормыш бу заман йоктырган
Чирдә терелсен, иде.
Их!...

***

Яши генә башладың ич,
Бар хаталы эшләрең.
Берсен дә кабул итмәдең,
Үтмәде киңәшләрем.

Үземне гаепләргәме,
Бөтен ялгышың өчен,
Бер сүз белән тыңлатырга
Җитмәгән өчен көчем.

Үкенерсең, мең газаплы
Ул көн җитәчәк.
Еламый дисеңме, сөю
Кояшыннан сакланмыйча,
Таҗлары көйгән чәчәк!

## ЯШИСЕМ КИЛӘ

Эшем бар, тәмле ашым бар,
Күпкәме бу, азгамы?
Алларыма килми калмас,
Маңгаема язганы.

Бүгенгә мин пар канатлы,
Ялгыз да калырмынмы?
Ялгызлык авырлыкларын
Күтәрә алырмынмы?

Бәхет кошым үләр микән?
Ул әле сайрап яши.
Күкләремдә күкләр күкри,
Яшеннәр әле яшьни.

Әлегә мин балкып яшим,
Сүнәрмен микән мин дә?
Шушындый куркыныч уйлар
Уйлыйсыңмы ул син дә?

Ярый ла, халкым күңелендә
Яшәсәм балкып, янып.
Тал гына булып булса да
Яшәргә иде язларда
Яфракларымны ярып!

Ц Б С Янаульского
района Баш. АССР
абонемент



112120

# ЭЧТӘЛЕГЕ

ҮЗЕМ ТУРЫНДА..........2
Авылда ир бала туса..........3
Адаштың хис –бураннарда..........3
Авыр хәлдә эткәй, алга түгел..........4
Бар мине дә рәнҗеткәннәр..........4
Авыр сулап куясың..........5
АКЫЛЫМА..........5
АВЫРНЫҢ ДА АВЫРЫ..........6
Ак кыш, ерак юлга чыгып..........7
Аракыны кемнәр уйлап..........7
АК ТӨС..........8
Артык авыртынмаганда,..........8
Акылсыз: «Мин акыллы!»..........9
АРТЫК ГОМЕР..........9
АКЫЛЫМ ҖАВАБЫ..........10
Бар яктымнан мине мәхрүм итте..........10
АНТЫБЫЗ БАР..........11
Бәхет ул кеше булып яши белү..........11
«Апа, аякларың кая..........12
Бар, ышанып, алданганым..........12
Апрель ае, кар суының..........13
БАЛА ТУДЫ..........13
АТ АТЛАНЫП ЧАБАРСЫҢ..........14
БӘХЕТЛЕМЕН..........14
Ат, йөгәнен чәйнәп, йөген тарта..........15
Баймын, ләкин минем байлык..........15
АЧАМ КҮҢЕЛ САНДЫГЫМНЫ..........16
БӘХЕТ КИРӘК БУЛСА..........16
Ашыгып китмә әле, кыш..........17
Бәхет кошы канатлы бит..........17
БАЗАРДА ЙӨРЕП КАЙТКАЧ..........18
Кайгы килә, ничек инде..........18
Бар иде ул минем ямьле язым..........19
МАКТАУЛЫ ИСЕМ АЛГАЧ..........19
Барам, юлда туктап калмыйм..........20
БАШЫҢ ТҮБӘН ИМӘ..........20
БАШКОРТСТАН..........21
Бугазымнан алсаң да, чир..........21
БАШКОРТСТАН БӨРКЕТЛӘРЕ..........22
Бүген дә бер авылдашым..........22
БӘЙРӘМДӘ..........23
ЭЗЛӘРЕҢДӘ ГӨЛЛӘР ҮСӘР..........23
БЕЛ..........24
БЕР ТАНЫШЫМА..........24
Берәү миннән бер сүз котте..........25
БЕРӘҮ ТУДЫ..........25
БӘХЕТ КИЛЕР..........26
Язларың үтеп киткәнгә..........26
БӘХЕТ ЮРАДЫМ..........27
ГАФУ ҮТЕНӘМ..........27
БӘХЕТЕМ ЗУР..........28
Биргәч бирә икән Ходай..........28
Бәхеткә ышан, бәхет бар..........29
Әйтерсең лә, кулларымда..........29
БӘХЕТЛЕ БУЛЫГЫЗ..........30
БҮГЕН..........30
БӘХЕТЛЕ ӨНЕМ БУЛ..........31
БҮГЕН ЯЗНЫ КӨТМӘСӘМ ДӘ..........31
БҮГЕНГЕ КӨН..........32
Гомеркәйләр шулай үтә икән..........32
Бүгенгедәй хәтеремдә..........33
Гомер буе бисмилласыз булгансың..........33
БУӘ БУЕНДА..........34
ШОМЛЫ ТӨН..........34
Бүләк иттең чәчәкләрнең..........35
Высший сортлы оннар булсын алар..........35
Илгиз хәзер алты яшьтә..........36
ГАДИ БУЛЫЙК..........36
ГАЕП ТҮГЕЛ..........37
ГАШЫЙК БУЛДЫМ..........38
ГАШЫЙКМЫН..........38
ГОМЕР КӨЗЕМ..........39
ГОМЕР УЗА!..........39
ГОРУРЛЫГЫМ..........40
ДУСТЫМА..........40
Гөлләр шатлана, чәчәккә..........41
Диңгездәге дулкын булдым инде..........41
ГӨЛЛӘР ҮСТЕР..........42
ГӨЛЛӘР КҮРӘМ..........42
Гөл - чәчәккә тиңлә мине..........43
Дөнья шулай яратылган,..........43
Давылларга каршы барачакмын..........44
Әй, кошкай, оян читенә..........44
Гөлсем җырлый, сандугачлар..........45
Елларымны, айларымны..........45
ЕГЫЛМЫЙЧА КӨРӘШӘМ..........46
Елый –елый үсә бала..........46
ЕЛМАЯМ..........47
Бер көнем дә бушка үтми, каләм кулда..........47
Әле генә кеше туды..........48
ӘГӘР ҮЛСӘМ..........48
Елый, көлә, сабый чак бу..........49
ӘНКӘЙДӘН СОҢ..........49
ҖИҢӘРМЕН..........50
Әнкәй дә юк, эткәй дә юк..........50
Әнкәй, бүген миңа авыр!..........51

Жырлап яшим.....................................51
Елыйм бугай.....................................52
Җәй башланды, күкрәк тутрып.....................................52
ЖАН БОРЧУЛЫ.....................................53
ЗАРЛАНМЫЙМ.....................................53
И көннәрнең матурлыгы.....................................54
Кем еласын бер кайгысыз.....................................54
ИЗГЕ ЮРАУ.....................................55
ӘРНҮ.....................................55
Көз, бир миңа бер матур җыр.....................................56
Изгелеген кылучылар.....................................56
Зәңгәр күлдә чумып уйный.....................................57
Күптәнмени бер -берегезгә.....................................57
Илле биш ул нәрсә генә.....................................58
Күтәрелсәң, әгәр күккә.....................................59
Ике тәлгәш җимешең бар.....................................59
ИСӘН ӘЛЕ АКЫЛ!.....................................60
Шифалы, саф һава монда.....................................61
Кемнәр шигырь яза? .....................................61
Инде күптән елаганым.....................................62
Имансызлар белән тулы донья.....................................62
Көтмәгәндә килеп җиткән.....................................63
Кайгы килгәч: «Түзәрме!».....................................64
КИТӘЛӘР ШУЛ.....................................64
Кабер туфрагына ятып ана елый.....................................65
Кем сындырды минем каенымны.....................................65
Кабер туфрагын кочаклап.....................................66
КӨТӘМ.....................................66
Йөзгә матур, бер күрүдә.....................................67
КӨЗ ЯМЕ .....................................67
КАЙСЫСЫН САЙЛАР ИДЕҢ?.....................................68
Китмә, жан, китмә, тәнемнән.....................................68
Кайгы күргән кеше кочле була.....................................69
Кулымнан төшми каләмем.....................................69
КИТМИ КАЛГАН КОШЛАРГА.....................................70
КИЛМӘ.....................................70
КЕШЕ ХАКЫНДА.....................................71
КӨТ МИНЕ .....................................71
КОЯШСЫЗ.....................................72
Күл буена барып шигырь таптым.....................................72
КОШ.....................................73
–Көннәреңне ниләр эшләп үткәрәсең?...73
КИЧЕР.....................................74
МАКТАМАМ .....................................74
КИЧӘ ҺӘМ БҮГЕН.....................................75
Коңгә баккан нәни бөре.....................................75
КӨЗЛӘР ЖИТТЕ.....................................76
Көзге төн булган ул, карлы төн.. .....................................76
КӨЗГЕ ЯҢГЫР.....................................77
Көз үзенең алтын яллы.....................................77
БЕЗНЕҢ УРАМГА .....................................77
КӨЗ ТӨСЕ.....................................78
КҮҢЕЛ БЕЛӘН АКЫЛ.....................................78
КҮҢЕЛ ТҮЗӘ.....................................79
Кыенсынма, сөйлә әле.....................................79
КУНАК КӨТӘМ.....................................80
Куркытырга дип кошларны.....................................80
Мамык шәлдән җылы әзлим.....................................81
КУРКЫТТЫ!.....................................81
КҮЧЕНГӘНДӘ.....................................82
Мәхәббәт –ул синең карашларың.....................................82
Күңелемне ачып кара әле.....................................83
МАТУР ЯЛГАН .....................................83
МАКТАРГА ЯРАТМЫЙМ.....................................84
КЫШКЫ УРМАНДА.....................................84
МАТУРЛЫК ЯШӘСЕН!.....................................85
МАТУРЛЫГЫҢ КҮРЕНЕР.....................................85
Матур хыял, тормышка аш.....................................86
Мин үлүдән куркам, үлсәм.....................................86
МИН ЫШАНАМ ЯҢА ЕЛГА.....................................87
МИН - ЧАЯН.....................................88
Мин доньяга килгән жир бу.....................................88
Илле биш яз килде сиңа.....................................89
МИНЕМЧӘ ШУЛАЙ.....................................89
Музей нигә кирәк? –дигән.....................................90
Күзләреңә карыйм кебек соңгы тапкыр.90
МОҢ ӨЗЕЛДЕ.....................................91
Еладым.....................................91
ӨЧ ТЕЛ.....................................92
Нур - кыллардан оя үреп.....................................92
Моң белән тулы күкрәгем.....................................93
Сине чәчәк, диеп була –гүзәлсең.....................................93
Ни генә юк бу тормышта.....................................94
НӘРСӘ БӘХЕТ?.....................................95
Нәкъ менә, бүгенге кебек.....................................95
Наилэгә бүген бер яшь.....................................96
ӨМЕТ.....................................96
ТУЙ АТЛАРЫ САГЫНДЫРА.....................................97
СҮЗ КӨЧЕ.....................................97
Өй буена агач утырталар.....................................98
Таш юлда күгәрчен канаты.....................................98
ӨЗЕЛГӘН ЧӘЧӘКЛӘР.....................................99
Яшәү уттан тора икән.....................................100
САГЫНАМ.....................................100
РӘХМӘТ, ЯҢА КӨН!.....................................101
САБЫР ИТ.....................................101
РӘХМӘТ СҮЗЕМ.....................................102
СИН ИДЕҢМЕ?.....................................102
РӘХМӘТ ӘЙТӘМ.....................................103
СӨЮ КӨТКӘН ЧАГЫМ.....................................103
Тамчы тама, ага гөрләвек.....................................104
Сату итү чире белән.....................................104

САГЫШЛЫ ТӨН........................105
Елавыннан, хәтта көлүеннән..........105
САГЫНМЫЙМ..............................106
Сугып авырттыра алмам.................106
СОҢГЫ ЧӘЧӘКЛӘР.......................107
Суз кулыңны, ярдәменә мохтажмын....107
Сирень, әле син кечкенә..................108
Тарәзәмә озын челтәр элгәнем юк......108
Серең дә бар, моңың да бар.............109
ТӘМ............................................109
СУГЫШ БЕТТЕ..............................110
СӨЮ КАБУЛ ИТ..............................111
Тормышта күп утлар йоттым.............111
Төнге янгыр– ялгызларның...............112
Сонгы жәем булма, жәем..................112
Тамагым тук, өстем бөтен.................113
Үз сүзле булдым, һаман да................113
ТАБИГАТЬКӘ РӘХМӘТ.....................114
Тараддылар кошлар төрле якка..........114
Таш кутәрмәдә эт ятә......................115
Түзәрмен, тулса гел тулсын..............115
ТАТАР КЕМ УЛ?.............................116
Хыянәт- ул саф күңелдән..................116
ТАНЫШЫМА..................................117
ХЫЯЛЫМДА КИЛӘЧӘГЕҢ...............117
ТЕЛӘГЕМ......................................118
ТУГРЫ КАЛАМ...............................118
Тәгәрәде күз яшьләрем....................119
Түзәм, дисәң түзеп була да бит..........119
ТУГАН КӨНЕМДӘ...........................120
ТОТКЫНДА ӘЛЕ ЯШЬЛӘР КҮП.......120
ТӨННӘРЕМ ЖЫРЛЫ........................121
Үзе иркен, нурга тулы күк булса да.....121
Хәтерли Кырлай яклары....................122
Үлем түшәгендә ята кеше..................122
ҮЛЕМ КИЛМӘСЕН...........................123
ҮЗГӘРДЕМ.....................................123
УКЫСЫННАР..................................124
Юк, ялгыш та әйтмә берүк...............125
Ут булып дөрләдем.........................125
ҮРНӘК АЛЫЙК................................126
Урам эте, шатлыгым бар...................126
ҮЛМӘС ӨМЕТ.................................127
Хәлләремне аңлый белмәгәннәр..........127
Ходай миңа таудай итеп...................128
Хисләремнең мөлдерәмә...................128
Хәмер исе килә үсмер кыздан.............129
Тәрәзәмдә боз эреде........................129
ХӘЕРЛЕ ЮЛ!..................................130
Чәчемне тарасын әле жил.................130
Хыял дәрьясында йөзәм....................131
ШАТЛАНЫЙМЧЫ..........................131
ХЫЯЛ!........................................132
Чирне жиңеп булмый аны...................132
ХУШЛАШУ..................................133
ЧЫН ӘЙТӘДЕР..............................134
Читлектәге кошның хәлен беләм.........134
ЧӘЧӘК ҮЛЕМЕ..............................135
Эт гомере буе өрә.........................135
ШАТЛЫГЫМА ЮРЫЙМ....................136
ШАТЛАНАМ................................136
Шәһәрдә дә язлар матур ләбаса..........137
ШАГЫЙРӘ МИН.............................137
ЫШАНДЫМ..................................138
Эчкән суым тәмле шәһәрдә дә............138
ЫШАНАМ....................................139
ШУНЫ БЕЛДЕМ............................139
ЭТКӘ..........................................140
Энже –энже булып сибелә кар............140
Әй, кешеләр, беләсез ич...................141
ЯЗ КИЛСЕН..................................142
ЯЗ ТАВЫШЫ.................................142
ЯҢА ЕЛ ЯКЫНЛАША.......................143
ЯВЫЗЛЫКНЫ ЖИҢӘР КӨЧ БАР....143
Явызлык күп, үлчәп кенә..................144
ЮЛДАМЫН..................................144
ЮК ЛА БАШКА ЧАРАСЫ..................145
Язны көтә күңел, әллә шуңа..............145
ЯЗМЫШЫМ..................................146
ЯЗМЫШТАШКА............................147
ЯКТЫ БӘЙРӘМ............................147
ЯЗАМ ӘЛЕ...................................148
–Яфрак, син бит яшел идең................148
Ялкын булсам – су сибәрләр..............149
Яратмыйм мин кешеләрнең................149
ЯКТЫ ӨМЕТ................................150
ЯЗНЫ КӨТҮ.................................151
ЯШӘРГӘ БУЛА БИТ.......................151
ЯҢГЫРЛЫ ТӨНДӘ.........................152
МӘЙДАНДА.................................152
ЯҢА ЯЗ......................................153
ЯШӘҮ МАТУР..............................153
ЯШӘРГӘ ИДЕ ӘЛЕ!........................154
ЯШӘП КҮРСӘТӘМ........................155
Яфраксыз калган каен –кыз...............156
Яши генә башладың ич....................156
ЯШИСЕМ КИЛӘ............................157
Эчтәлеге.....................................158

Литературно-художественное издание

**Кәүсәрия Шафикова**

**АЧАМ КҮҢЕЛ САНДЫГЫМНЫ**

Шигырьләр
(татар телендә)

Редакторы *Ф.Ф. Аскарова - Галиева*
Техник редакторы *Ә.Г. Латыйпова*

Җыярга бирелде 05.06.07. Басарга кул куелды 26.06.07. Кагазь форматы А 5. Офсет кәгазе. Әдәби гарнитура. Ризографта басылды. Шартлы басма таб. 3,60. Учет-нәшер. таб. 2,60. Тиражы 500 данә. Заказ № 832. Хакы ирекле.

**ООО "НУР"**

90